## КОРБАН ГАЕТЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!



**Укучыбыз соравына Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров җавап бирә**

7 бит


## ТАТАР ДИН ГАЛИМНӘРЕ ЕЛЫ



**Казанның соңгы ишаны – Гарифулла хәзрәт кызы Зөбәрҗәт Мөхәммәтҗанова хатирәләре**

11 бит

## ГЫЙБАДӘТ АСЫЛЫ



**Дога кабул булсын дисәң...**

12 бит


# ДИН вә Мәгыйшәт

6+

*Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! (Коръән, 3:103)*

*Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!*

№ 9 (242). СЕНТЯБРЬ – 2015 / ЗӨЛКАГДӘ – ЗӨЛХИҖҖӘ – 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



реклама

AZAN ИСЛАМ АВАЗЫ ИНТЕРНЕТ-РАДИОСЫ

www.radioazan.ru


# Корбан бәйрәме Аллаһның рәхмәтенә якынайта



**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Әссәләәму гәләйкум үә рахмәтуллаһи үә бәрәкәәтүһ! Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык дин кардәшләребезне Корбан гаете белән котлыйм! Күркәм бәйрәмебез Корбан гаете мөбарәк һәм хәерле булсын! Барчаларыбызга иминлек, игелек, бәрәкәт алып килсен!**

Корбан чалу гыйбадәте Аллаһка якын булу һәм аның нигъмәтләренә шөкер итү өчен башкарыла. Корбан чалу ул Раббыбызның бер әмере. “Кәүсәр” сүрәсендә Аллаһы Тәгалә: “Раббың ризалыгына намаз укы. Корбан чал”, – дип боера (2 нче аять). “Хаҗ” сүрәсендә: “Без һәр өммәткә корбан чалуны тәртип иттек. Үзләренә ризык булырга тиешле, дүрт аяклы малларны корбан итеп чалганда Аллаһ исемен телгә алсыннар, дип. Сезнең Раббыгыз – Ул бердәнбер – Аллаһ. Шулай булгач, Аңа тәслим итегез. (Ий, Мөхәммәд) син ихлас күңеллеләрне һәм тыйнак итагатьчеләрне сөендер”, – ди (34 нче аять).

Корбан бәйрәме изге сәфәр – хаҗ кылу тәмамланган көн дә. Пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи вә сәлләм) бер хәдисендә әйтә: “Аллаһ каршында көннәрнең иң бөеге – Корбан бәйрәменең беренче көне, аннан соң хаҗилар Минәдә карар кылган икенче көндер”, – ди. Безнең ватандашларыбыз да миллионлаган мөселманнар белән бергә Кәгъбәдә очраша. Аллаһы Тәгалә аларның хаҗларын кабуллардан кылсын һәм туган илебезгә исән-имин әйләнеп кайтырга язсын.

Аллаһы Тәгалә күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалган корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт тормышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде. Корбан бәйрәме мөбарәк булсын!

**Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
**Татарстан мөселманнары**
**Диния нәзарәте рәисе**

***

Татарстанның барлык мәчетләрендә бәйрәм намазы кояш чыгу вакытыннан соң ярты сәгать узгач укыла. **24 сентябрьдә Казанда кояш 5 сәгать 31 минутта** чыга, **бәйрәм намазы сәгать 6.00 дә** башлана.

***

Диния нәзарәтенең Казыйлар һәм Голәмалар шурасы җыелышында корбан нисабы күләме тәгаенләнде, ул – **17 мең сум.** Гаиләдә артык 17 мең сум акча булганда, корбан чалу ваҗиб, мәҗбүри санала.

### Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН:

# “ҺӘРКЕМГӘ ЯРДӘМ КУЛЫ СУЗАРГА КИРӘК”

**Корбан бәйрәме хәйриячелеккә этәргеч бирә, эчкерсезлек, шәфкатьлелек тәрбияли. Юмарт була белгән һәм якыннарының проблемалары турында онытмаган кеше генә саваплы була, дип исәпли мөселманнар. ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин белән без әнә шул һәм башка мәсьәләләр турында сөйләштек.**



**- Камил хәзрәт, интервьюларның берсендә сез: “Кайдадыр аңлашылмаучанлык килеп чыкса, мин бу районга үзем барам, кешеләр белән аралашам. Конфликтны ерактан чишеп булмый, килеп чыккан хәлне төшенеп, кешеләрне тыңлагач кына компромисска килергә була”,- дигән идегез. Компромиссны һәрвакыт табып буламы?**

- Әлбәттә. Бөтен низаг һәм бәхәсләр мәгълүмат һәм белем җитмәүдән килеп чыга. Нәкъ менә шуңа күрә Диния нәзарәтенең төп эшчәнлегенең берсе - мәгариф. Мәсәлән, без имамнар өчен квартал саен “Шура” журналын чыгарабыз. Йөз ел элек аны танылган галим, “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенә нигез салучы, патша хакимиятеннән соң безнең җирлектә билгеләнгән беренче мөфти Галимҗан Баруди чыгара. Ә бүген һәр санда революциягә кадәр чыккан журналда басылган мәкаләләр, фәтвалар, хәнәфи мәзһәбе нигезләре буенча аңлатмалар, вәгазьләр чыга. Руханилар анда четерекле сорауларга, үсеп килүче буынга тәрбия һәм белем бирүгә караган сорауларга җаваплар, дини йолаларны үтәү тәртибе һәм башка кыйммәтле мәгълүматны таба ала. Без җомга вәгазьләре җыентыгын тупладык, бу Татарстан мәчетләрендәге җомга вәгазьләренең бер рәвешле үткәрелүенә китерде. Республикадагы мең ярымга якын мәчетнең һәрберсе өчен мин тыныч.

**- Сезнеңчә, республикабыз ИГИЛ кебек радикаль һәм экстремистик агымнардан ышанычлы якланамы?**

- Казан һәрвакыт татар халкының рухи үзәге булып торган. Илебездә ислам динен беренче булып, хәтта кайбер гарәп илләреннән дә алданрак татарлар кабул иткән. Горурланырлык сәбәпләр дә бар, бай тарихыбыз безне берләштерергә тиеш, шуңа нигезләнеп эш итәргә тиешбез. Без террорчылар һәм золым кылырга өндәүчеләр белән беркайчан да уртак тел тапмаячакбыз. Безнең алар белән диалог гомумән була алмый. Шуңа күрә берничә ел элек Татарстан урманнарында өч мең ваһһабчы яшеренеп ятуы турында таратылган гайбәтләрне берничек тә аңлап булмады. Бүгенге көндә тискәре, бернәрсәгә дә нигезләнмәгән мәгълүматны тарату бик җиңел. Моның өчен күп көч түгәргә кирәкми, бары тик социаль челтәрләргә керү дә җитә. Ә менә ИГИЛ тарафдарларына һәм аларга якын агымнарга чик куюу җиңел түгел. Бу күренешкә каршы Диния нәзарәтенә генә түгел, барыбызга да көрәшергә кирәк. Мин күптән түгел Әбү-Дабида узган төрле илләрдән килгән дин белгечләре катнашындагы конференциядән кайттым. Анда шундый сорау каралды: ни сәбәпле яшьләр радикаль төркемнәргә керә, алар нинди дәлилләргә каршы тора алмый? Моны аңлар өчен, бу оешмалар җитәкчеләренең хезмәтләрен өйрәнергә кирәк. Сорау ИГИЛ турында гына түгел, ә гомумән, ислам диненең традицион кысаларыннан чыккан теләсә нинди агым турында. Нәтиҗәләр белән түгел, ә сәбәпләр белән көрәшергә кирәк. ИГИЛ кебек агымнар артында нинди генә көч торса да, алар кылган гамәлләр бөтен мөселманнарга җитди зыян китерә.

**- Республикабызда ислам диненең киләчәген ничек күрәсез? ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршында беренче булып нинди бурычлар тора?**

- Татарстанның бөтен өлкәдә дә әйдәп баруы сер түгел. Дини мәсьәләләрдә дә без артта калучылардан була алмыйбыз, бигрәк тә илебездәге мәчетләрнең 26%ы республикабызда урнашкан булгач. Күрше регионнар да безгә кушылырга теләгәннәр иде. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, ислам имиджын ясауга зур игътибар биреп, төрле өлкәләрдә актив эшли. Бездә Казыйлар шурасы, Голәмалар шурасы бар. Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев – бай һәм зирәк тормыш тәҗрибәсе туплаган кеше. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Укыту-методик берләшмәсе Татарстанның ун мәдрәсәсе өчен дә бердәм укыту программасы өстендә эшли. Без, укыту программасы Ш. Мәрҗани, М.Бигиев, Г.Баруди, Р.Фәхретдин кебек татар галимнәре хезмәтләренә нигезләнергә тиеш, дип исәплибез. Болар - югары дәрәҗәдәге көнчыгышны өйрәнү белгечләре. Бүгенге көндә дөньякүләм дәрәҗәдәге, танылган ислам галимнәрен тәрбияләү ихтыяҗы бар. Моның өчен төп нигез – Россия ислам институты...

Актив эшчәнлек алып барылган тагын бер юнәлеш – иҗтимагыйсоциаль хезмәт. Ярдәм мәчетендә сукырлар белән зур эш алып барыла, мәчет имамы Илдар хәзрәт Баязитов – командабызда социаль проектларның җитәкчесе. Бүген безгә хәмергә бәйле булган, төрмәләрдән чыккан кешеләрне тернәкләндерү үзәкләре җитми. Көчебездән килгән кадәр аларга ярдәм кулы сузарга кирәк. Әлбәттә, без мәчетләргә ярдәм күрсәтү турында да уйлыйбыз. Кайвакыт рухи тәрбия бирү белән шөгыльләнү урынына имам мәчетне тоту өчен акча эзләү белән мәшгуль. Кемдер сәдака акчасына гына яши, кемдер параллель эш белән шөгыльләнә: китаплар бастыра, кибет тота. Без район башлыкларына имамнарга булышлык күрсәтүнең мөһимлеген аңлатырга тырышабыз, чөнки авылдагы сәясәтне имам билгели, абруйга ия булса – бигрәк тә.

**- Билгеле булганча, Сез Интернетта бик актив, блог алып барасыз, социаль челтәрләрдә сорауларга җавап бирәсез, теге яки бу күренешләрне аңлатасыз. Диния нәзарәте заман белән бергә атлый...**

- Фән һәм техника үсеше, бүгенге заман технологияләрен кире кагу дөрес булмас иде. Мөселманнар фән казанышларын ислам динен тарату өчен кулланырга тиеш. Ислам җәмгыять өчен бер файдалы яңалыкны да кире какмый. Шуңа күрә без эшебездә бүгенге заман казанышларын файдаланырга тырышабыз. Безнең үз сайтыбыз, радиобыз бар. Хәзер чираттагы проект – үз телефоныбызны булдыру өстендә эшлибез.

**- Диния нәзарәтенең “Хәләл” стандарт комитеты 2005 елның ахырында булдырылды. Бүгенге көндә ничә эшмәкәр һәм ничә сату оешмасына комитет тарафыннан таныклык бирелде?**

- Һичшиксез, сүз экологик яктан чиста, иң мөһиме - мөселманнарга рөхсәт ителгән, продукция турында бара. Безнең максат – мөселманнар өчен файдалы ризык әзерләүгә шартлар тудыру, алар моңа мохтаҗ булуларын аңлыйлармы – монысы башка мәсьәлә. Без бирә торган сыйфат билгесе – алдыгызда хәләл ризык торуга дәлил. Бу билге артында зур оешма, тулы бер система тора. Мөселман кешесенең ризыкның ни рәвешле һәм нинди шартларда эшкәртелгәнен, тыелган ризык белән кушылмаганмы, кафе турында сүз барганда, анда хәмер сатыламы-юкмы икәнлеген белергә хакы бар. Кайбер намуссыз эшмәкәрләр дә, хәләл ризыкны сатуның керемле булуын күргәч, бу марканы үз максатларында кулланырга булдылар. Моның белән ничек көрәшергә? Күп нәрсә мөселманнарның үзләреннән тора. Мөхәммәд Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дигән: “Тыелган һәм рөхсәт ителгән – билгеле, алар арасында – шикле. Шиклене калдырыгыз. Әгәр дә калдырмасагыз, ул тыелганга китерә”. Сатып алучының принципиаль позициясе фальсификациянең юкка чыгуына китерергә тиеш. Без “хәләл” таныклыгы биргән һәр оешманы катгый рәвештә тикшереп торабыз – малны чалудан алып әзер ризыкны сатуга кадәр күзәтәбез. Ышанычны югалткан эшмәкәрнең таныклыгын кире алу очраклары да була. Бүгенге көндә РТ Диния нәзарәтенең “хәләл” таныклыгы 85 җитештерүчегә һәм кафега бирелде.

**- Камил хәзрәт, Сез дини кагыйдәләрне бала чактан ук өйрәндегезме?**

- Мин 11 яшьтән мәчеткә йөри, 14 яшьтән намаз укый башладым. Беркем дә мәҗбүр итмәде, бу - үз ихтыяҗым иде. Кесәдә йөргән акчага “Иман” нәшрияты китапларын сатып ала идем, аларның бәясе очсыз, эчтәлекләре минем өчен бик кыйммәтле иде. 9 классны тәмамлагач, “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенә кердем, бер үк вакытта Казан мәктәпләренең берсендә укыдым. Соңрак Дагыстан башкаласы Махачкаладагы Төньяк-Кавказ ислам университетына укырга кердем. Аны тәмамлагач, белем алуны Стамбулда дәвам иттем һәм шәригать гыйлемен укырга иснад белән рөхсәт (иҗәзә) алдым (иснад - Әбү Хәнәфи аша Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) үзенә кадәр барып җитә торган чылбыр). Бу бик мөһим документ, чөнки миңа аны танылган дин белгече бирде. Ул аны, үз чиратында, үзенең укытучысыннан алган, анысы – үзенекеннән, шулай итеп, чылбыр Пәйгамбәребезгә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) кадәр барып җитә. Белемнең буыннан-буынга тапшырылуы – динебезнең аерылгысыз өлеше. Шундый чылбыр булган очракта гына рухи җитәкчегә ышанырга була.

**(Ахыры 3 нче биттә.)**

# “Остазлар мирасын саклауда Вәлиулла хәзрәткә җиткәне юктыр...”



**4 сентябрьдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам институты белән берлектә дүртенче мәртәбә “Якупов укулары” фәнни-гамәли конференциясен үткәрде. Әлеге чара 2012 елда фаҗигале төстә вафат булган киң танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе Вәлиулла хәзрәт Якупов эшчәнлегенә багышланды.**

“Якупов укулары”нда катнашкан Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин: “Вәлиулла хәзрәт нибары ике дистәгә якын вакыт эчендә динебез үсешенә феноменаль өлеш кертеп калдырган шәхес. Яңа заманда аның кадәр татар дин галимнәрен белгән, өйрәнгән, шул ук вакытта аларның хезмәтләрен бастырган, нәшер иткән һәм халыкка тараткан башка галим юк. Остазларыбызга хөрмәт күрсәтүдә һәм алар мирасын саклауда аның дәрәҗәсенә җиткән дин әһеле дә юктыр әле”, - дип, хәзрәтнең хезмәте хакында сөйләде. Ул үзенең чыгышында Вәлиулла хәзрәтнең олуг бер хезмәте мәдрәсәләр белән бәйле булуына да игътибар юнәлтте. “Инкыйлабка кадәрге мәдрәсәләр татарларга диннәрен, иманнарын саклауда калкан булган. Вәлиулла хәзрәтнең дини гыйлем бирүдә сыналган һәм төпле нигез булган мәдрәсәләр системасын кире кайтаруда өлеше гаять зур”, -диде.

Шулай ук мөфти Вәлиулла хәзрәт Якупов башлаган эшләрнең дәвамлы булуын теләде: “Без быелгы елны татар дин галимнәрен өйрәнү елы дип игълан иттек. Бу Вәлиулла хәзрәт башлаган эшләрне дәвам итү булып тора. Яшьләребез дә тартылсын дип фәнни язмалар конкурсы игълан иттек. Конкурс яшьләрне татар дин әһелләре мирасын, аларның хезмәтләрен өйрәнүгә җәлеп итү, районнардагы татар дин әһелләре мирасын барлау, ватанпәрвәрлек, толерантлык кебек сыйфатларны тәрбияләү максатыннан уздырыла. Раббыбыз эшләребездән разый булып, гамәлләребезне, догаларыбызны кабуллардан кылса иде. Алга таба да зыялы дин әһеле, остаз Вәлиулла хәзрәтнең эшен дәвам итәргә язсын. Мәрхүмнең рухы шат булсын”.

“Якупов укулары”нда мөфти урынбасары Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин, Коръәнне һәм сөннәтне өйрәнү үзәге җитәкчесе Фәрид хәзрәт Сәлмән, Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров һәм башка дин әһелләре, Вәлиулла хәзрәтнең хезмәттәшләре, галимнәр чыгыш ясады. Аларның һәркайсы Вәлиулла хәзрәт Якуповны олылап искә алды.

# Рөстәм Миңнеханов ТР Президенты вазыйфаларына кереште

**13 нче сентябрьдә үткән Татарстан Президенты сайлауларында сайлаучыларның 94,4 процент тавышын җыйган Рөстәм Миңнеханов Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кереште. Татарстан Президенты инаугурациясе тантанасы С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында узды. Тантананы ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ачты. Аннары залга Россия һәм Татарстан дәүләт флаглары, шулай ук Президент штандарты кертелде. Рөстәм Миңнеханов, Конституцияләргә кулын куеп, ант текстын әйтте. Соңыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гимннары яңгырады.**

# Мәккәдәге фаҗигадә татарстанлылар зыян күрмәде

**Мәккәдә, дөньядагы иң зур мәчеттә килеп чыккан фаҗигадә Татарстан хаҗилары зыян күрмәде. Мәгълүм булганча, 11 сентябрь көнне Әл-Хәрам мәчете янында төзелеш краны аву нәтиҗәсендә, 111 кеше һәлак булды, 200 дән артыгы тән җәрәхәте алды.**

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин фаҗига уңаеннан кайгы уртаклашуын белдерде. “Татарстан мөселманнары исеменнән һәлак булучыларның туганнары һәм якыннарының кайгысын уртаклашам һәм Аллаһы Тәгаләдән зыян күрүчеләрнең тизрәк савыгуын сорыйм... һәлак булучылар - ихластан Аллаһыдан ризалык алырга һәм Аңа якынаерга теләүчеләрдән, Аның алдында бурычларын үтәргә омтылган дин кардәшләребез. Аллаһы Тәгалә гөнаһларын кичереп, аларны җәннәтле итсен дип телибез...” - диелә Камил хәзрәт Сәмигуллин кайгынамәсендә.

# "СӨЮЧЕЛӘР ФИДА КЫЛА" ТЕЛЕМАРАФОНЫНДА КАТНАШЫРГА ЧАКЫРАБЫЗ

**ТР МДН өченче мәртәбә "Сөючеләр фида кыла" телемарафонын оештыра.**

24 сентябрьдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте "Яңа гасыр" телеканалы белән берлектә “Ярдәм” фондының “Гаилә җылысы” инвалид ятимнәрне тернәкләндерү приютындагы балаларга ярдәм итү максатыннан "Сөючеләр фида кыла" телемарафонын уздыра.

2013 елда үткәрелгән марафон нәтиҗәсендә Теләче районының Җөри авылында ике бина алынды, үзәкне оештыру эшләре җайга салынды. 2014 елда марафонда катнашучылар ярдәмендә биналар әнисез, әтисез, аның өстенә сәламәтлекләре начар булган балаларны кабул итәрлек дәрәҗәгә җиткерелде. Балаларга махсус медицина җиһазлары алынды, үзәкнең тирә-юнендәге җирлек тәртипкә китерелде.

Быел Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте янә барчабызны марафонда катнашырга һәм хәйрия эшенә үз өлешебезне кертергә чакыра. Телемарафон балаларны дәвалау өчен шартлар тудыру ниятеннән оештырыла.

Марафонда катнашу өчен 7715 номерына "Нур" сүзен язып SMS җибәрергә кирәк һәм телефон счётыннан инвалид ятим балаларның тернәкләндерү үзәге счетына 50 сум акча алыначак (төгәл сумма операторга бәйле). Сәдака бирергә теләвегезне раслауны сорап, җавап SMS киләчәк. Бу бик мөһим: раслаусыз акчаларыгыз балаларга барып җитми.

Әгәр сез зуррак сумманы күчерергә теләсәгез, "Нур" сүзеннән соң буш ара (пробел) калдырып, күчерергә теләгән суммагызны языгыз. Иң мөһиме – расларга онытмагыз. Шулай итеп, 7715 номерына "Нур" сүзе белән SMS яки "Нур" буш ара (пробел) һәм сез күчерергә теләгән сумманы язып SMS җибәрергә кирәк.

Аллаһы Тәгалә сәдакаларыгызны кабул итсен һәм безгә – ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә булышырга һәрвакыт мөмкинлек биреп торсын.

**ТР МДН матбугат хезмәте**

## Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН:

# “ҺӘРКЕМГӘ ЯРДӘМ КУЛЫ СУЗАРГА КИРӘК”

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

**- Тиздән бөтен дөнья мөселманнары Корбан бәйрәмен билгеләп үтәчәк. Бу бәйрәмнең рухи мәгънәсе нәрсәдә?**

- Бәйрәм иң игелекле һәм якты хисләр белән сугарылган, кешеләрне якынайтуга, җәмгыятьтә шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек һәм үзара хөрмәт идеалларын билгеләүгә хезмәт итә. Кирәкмәгән нәрсә белән хушлашырга бик җиңел. Ә сез үзегезгә якын һәм кыйммәтле булган әйберегезне биреп карагыз. Кешенең рухи үсеше өчен ике канат булуы кирәк. Матди мәсьәләләрдә үзебездән түбән булучыларга карарга, ә рухи сорауларда – югары булучыларга. Корбан бәйрәменең мәгънәсе - Ибраһим пәйгамбәр (галәйһиссәләм) кебек Аллаһы Тәгаләгә корбан китерү, шул иттән ризык пешереп, туганнарны, якыннарны, күршеләрне һәм теләгән кешеләрне сыйлау. Әгәр дә байлар бүлешә башласалар, бай һәм фәкыйрьләр арасындагы куралмаучанлык бетәчәк. Корбан бәйрәме Ибраһим (галәйһиссәләм) пәйгамбәрнең улы Исмәгыйльнең корбан булудан котылуы турында искә төшерә. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләгә һәр көнебез өчен, безгә күрү, ишетү, тою, йөрү сәләтен биргәне өчен рәхмәтле була белергә кирәк. Чын күңелдән мөселманнарны уртаклашырга өйрәтүче шушы бөек бәйрәм белән котлыйм. Ул безгә тынычлык һәм игелек алып килсен. Аллаһы Тәгалә барлык сәдака бирүчеләрнең, туганнарының хәлләрен белүче, ата-бабаларын искә төшерүче, фәкыйрь һәм мохтаҗларга ярдәм кулы сузучыларның догаларын кабул кылсын иде. Корбан бәйрәменә Аллаһы Тәгалә нәкъ менә шушы мәгънәне салган. Туганнарыгызны, якыннарыгызны котларга онытмагыз, аларга күңел җылыгызны бүләк итегез.

**- Рәхмәт Сезгә, Камил хәзрәт!**

**Альбина ХАҖИЕВА
(“Элита Татарстана” журналыннан кыскартып алынды)**

# “Һәрбер хак иясенә

## Бәйрәм

**Безнең күңелләребезне иман, ислам нуры белән нурландырган Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә чиксез хәмед һәм шөкраналарыбыз булса иде. Бөтен мәхлукатның хәерлесе булган, безгә бәхет-сәгадәт юлын күрсәтеп калдырган сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллəллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.**

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга үзенең чиксез сәламен, киң рәхмәтен һәм бәрәкәтен ирештерсә иде!

Хөрмәтле мөселманнар! Елга бер мәртәбә була торган бөек бәйрәмебез – Корбан гаете барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидәят биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен. Мөкатдәс Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып Аллаһы Тәгаләнең иксезчиксез рәхмәтләренә ирешергә насыйп булсын!

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышанып, Аның кушканнарын үтәп, тыйган гамәлләреннән тыелып яшәү – кешенең төп вазыйфасы булып тора. Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә кешене бу дөньяга нәкъ менә шуның өчен җибәрде дә. Һәрбер мөселман үзенең Раббысына омтылырга, Аны искә алырга, һәрбер гамәлне Аның ризалыгы өчен кылырга тиеш, чөнки ул бары тик Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте аркасында яши. Кайвакыт кеше үз Раббысын онытып, хаталар, гөнаһлы гамәлләр кыла, үзен һәлакәт чокырына ташлый, калебен каралта. Шушы гөнаһлардан, хатакимчелекләрдән пакьләнү, Аллаһы Тәгаләгә якынаю юлларының берсе – хаҗ гыйбадәте. Бөтен ислам галимнәренең уртак фикере буенча, хаҗ гыйбадәте һәрбер хәлле мөселман өчен фарыз (тиешле) гамәл булып тора. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ***“Мөмкинлекләре булган кешеләрнең Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычлары – Аның йортына хаҗ кылу”*** *(“Әли Гыймран” сүрәсе, 97 нче аять).*

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллəллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә әйткән: *“Әгәр берәү хаҗ кылып бозыклык кылмаса – әнә анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып кайтыр” (Бохари, Мөслим, Нәсаи).*

Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә – хаҗиларыбыз хаҗ гыйбадәтенең төп гамәлләрен тәмамлап, ихлас күңелләре белән Кәгъбәтуллага юнәлеп, тәлбия, ягъни: ***«Ләббәйкәллаһүммә ләббәйк. Ләббәйкә ләә шәриикә ләкә, ләббәйк! Иннәл-хәмдә вәннигъмәтә ләкә вәл-мүлк, ләә шәриикә ләк!»*** *(“Йә Аллаһы, менә мин Синең каршыңда! Менә мин синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк! Барча мактау Сиңа гына, барлык нигъмәт һәм хөкем Синең кулыңда гына! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк!”),* – дип әйтәләр.

Төрле илләрдә яшәүче ничәшәр йөз миллион мөселманнар кебек, без дә изге Корбан гаетенә шатланып, тәһарәт-гөселләр алып, пакь, матур киемнәр киеп, хушбуйлар сөртеп, тәкбирләр әйтеп, Аллаһы йортына – ягъни мәчеткә җыелабыз.

*Корбан* сүзе нәрсәне аңлата соң? Корбан гарәпчәдән *якынаю, якын булу* дип тәрҗемә ителә. Без бу мөбарәк бәйрәмдә Гает намазларын укып, Аллаһы ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып, Аллаһының рәхмәтенә якынаябыз, шуңа күрә бу олуг бәйрәмебезне шатланып каршы алабыз.

Корбан гаете барлык мөселманнарны берләштерә, якынайта, аларның күңелләре сөю, хөрмәт, бер-береңә миһербанлык һәм шәфкать хисләре белән тула. Бу мөбарәк көнне нәфрәт һәм ачулар юкка чыга, дошманлык һәм үпкә хисләре бетә.

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһының рәхмәтенә якынайта торган изге Корбан бәйрәме тирән мәгънәгә ия. Гарәпчә бу бәйрәм *Гыйд әләдха* дип атала. *Әдха* сүзе корбан чалу дигәнне аңлата. Мәгълүм булганча, корбан чалу йоласы безгә Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәламнән калган. Без корбан чалганда шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгаләгә корбанның ите дә, каны да кирәк түгел, Аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешә. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз Коръәндә үзе әйтә: ***“Аларның (корбанга чалынган хайваннарның) ни ите, ни каны Аллаһыга түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына ирешә. Сезне тугры юлга бастыручы Аллаһының бөеклеген танырсыз, (Аңа тәкбир әйтегез) дип бу хайваннарны шулай итеп сезнең файдагызга бирдек. (Йә Мөхәммәд), игелек кылганнарны сөендер”*** *(“Хаҗ” сүрәсе, 37 нче аять).*

Тәкъва булган, Аллаһыны чын күңелдән сөйгән кеше корбанны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалып, гаиләсен, килгән кунакларын һәм күршеләрен, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне хөрмәт итә, аларның күңелләрен күтәрә. Шулай итеп, ул Аллаһының ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кыла. Коръәни Кәримдә әйтелгән: ***“Әй иман китергән кешеләр, гөнаһ эшләп, Аллаһы каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Аңа якынлашырга юллар эзләгез, Аның юлында җиһад кылыгыз (тырышыгыз): бәхеткә ирешерсез”*** *(“Маидә” сүрәсе, 35 нче аять).*

**Корбан сүзе нәрсәне аңлата соң? Корбан гарәпчәдән якынаю, якын булу дип тәрҗемә ителә. Без бу мөбарәк бәйрәмдә Гает намазларын укып, Аллаһы ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып, Аллаһының рәхмәтенә якынаябыз, шуңа күрә бу олуг бәйрәмебезне шатланып каршы алабыз**

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әгәр без Аллаһы газабыннан котылырга һәм Аның рәхмәтенә ирешергә, бәхетле булырга теләсәк, алдагы аятьтә әйтелгәнчә, ислам юлында тырышырга, ягъни Корбан бәйрәме көннәрендә генә түгел, ә һәр көнне гөнаһлардан сакланып, Аллаһыга шөкрана кылып, күбрәк игелекле гамәлләр эшләп яшәргә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә *«Бәкара» сүрәсенең 29-30 нчы аятьләрендә* болай дип әйткән: ***“Җир йөзендә ни булса – Ул барысын да сезнең өчен яралтты. Соңрак күкне төзергә теләде һәм аны җиде кат итеп корды. Ул – барысын да белүче. (Йә Мөхәммәд), исеңдә тот, Раббың фәрештәләргә әйтте: “Мин Җир йөзенә (Адәмне) хәлифә (башлык, хуҗа) итеп яралтачакмын”. Фәрештәләр әйтте: “Без Сине мактап, тәсбих әйтеп, Аллаһы Тәгалә кимчелекләрдән азат дип Сине зурлап торганда, Җир өстендә азгынлык кылачак һәм кан коячак бәндәне хәлифә итеп куячаксыңмы?” – диделәр. (Аллаһы аларга) әйтте: “Сез белмәгәннәрне, һәрхәлдә, мин беләмен”.***

Шул рәвешле, Аллаһы Раббыбыз Адәм балаларын күркәм сурәттә яралтып, акыл, зиһен биреп, барлык мәхлуклардан өстен кылган. Аллаһы Тәгалә җир өстендә һәм астында булган байлыкларны, судагы хисапсыз күп балыкларны, бөтен җан ияләрен безгә буйсынучы, итагать итүче итеп яралткан. Безгә – Адәм балаларына – бернинди мәхлукка бирелмәгән хәлифә дәрәҗәсе бирелгән. Аллаһы Раббыбыз безне шундый олуг нигъмәтләр белән бүләкләгәннән соң, безгә зур гына вазыйфалар, бурычлар йөкләгән. Коръәни Кәримдә *“Тәхрим” сүрәсенең 6 нчы аятендә* адәмнәр өстендәге олуг вазыйфаларның кайберләре искә алына. Шул вазыйфаларны үтәмәүчеләрнең каты газапка дучар булачаклары турында белдерелә: ***“Әй иманлы бәндәләр, үзегезне, гаиләгезне уттан саклагыз. Ул утның утыны кешелек вазыйфаларын, кешелек бурычын үтәмәгән адәмнәр булыр”.***

Шулай итеп, Аллаһы Раббыбыз бу аять белән безгә белдерәдер ки, үзебезне һәм гаиләбезне дөнья, ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булган начар эшләрдән тыеп, җәһәннәм газабыннан сакларга куша. Өстебездә булган зур бурычларыбыз хакында Рәсүл әкрам галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: *“Әй бәндә, синең өстеңдә Раббыңның хакы, нәфесең һәм әгъзаларыңның һәм гаиләңнең хакы бар, һәрбер хак иясенә хакларын бир, вазыйфаңны үтә”.*

<u>Беренче вазыйфа</u> – Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә каршында булган вазыйфа, ягъни дөньяны, бөтен галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһыны тану, биргән барлык нигъмәтләренә шөкрана кылып, һәрвакыт һәр җирдә Аллаһы хозурына барып, хисап бирәчәгебезне истә тоту.

<u>Икенче вазыйфа</u> – кешенең үзе хакындагы вазыйфа, ягъни Аллаһы биргән тән сәламәтлеген саклау. Авыру булса – дәвалану. Күп кенә тән авырулары дөрес тукланмаудан килә. Бүгенге көндә без чамадан тыш күп ашыйбыз-эчәбез, ашказаннарыбызга ял бирмибез. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм ашказанын өчкә бүләргә кушкан: *бер өлеше – ризык өчен, бер өлеше – су, бер өлеше һава өчен (Тирмизи).* Аллаһы Раббыбыз бу хакта Үзенең китабында да әйткән: ***“Ашагыз, эчегез, ләкин исраф кылмагыз. Аллаһы исрафчыларны сөйми”*** *(“Әгъраф” сүрәсе, 31 нче аять).*

Күп ашау кунак сыйлаганда һәм сәхәр вакытында гына дөрес санала. Без һәрвакыт дөрес туклануга игътибар итәргә тиеш, чөнки авыруларның яртысы ризыктагы матдәләр аша килә. Мәсәлән, шәригатьчә бугазланмаган хайваннарның итләрендә зарарлы матдәләр күп була. Ризыкны яхшы ният-фикер белән әзерләү шулай ук мөһим булып тора. Сырхаулык килгәнче сәламәтлегебезнең кадерен белик.

Аллаһының Рәсүле галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә: *“Пакьлек (чисталык) – иманның яртысы”,* – дигән *(Мөслим, Тирмизи).* Шуңа күрә, суны еш кулланырга, һәрвакыт тәһарәтле килеш йөрергә тырышу лазем. Су – яшәү чыганагы: суны никадәр күбрәк куллансак, сәламәтлегебез шулкадәр яхшырачак.

Адәм баласының үзе хакындагы икенче бурычы – акылны гыйлем белән баету. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: *“Белем алу – һәрбер мөселман

# хакларын бир, әй бәндә...”

## вәгазе



өчен фарыз (тиешле)”, – дигән (Ибн Маҗәһ).

Мөселман кешесе дөньяви гыйлемме, дин гыйлемеме – икесен дә тигез күреп, аларны өйрәнергә бурычлы, чөнки дөньяви белем белән дини гыйлем, үзара бәйләнгән рәвештә, бер-берсен тулыландыра гына.

Адәм баласының үзе хакында өченче бурычы – күңелен, җанын тәрбияләп, аны начар сыйфатлардан арындырып, күркәм сыйфатлар белән бизәп, бөтен кешеләр белән дус, тату, тыныч торырга һәм игелекле гамәлләр кылырга тырышу. Рәсүл әкрам саллләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: *«Аллаһы Тәгалә сезне тышкы кыяфәтегез һәм матди байлыгыгыз буенча бәяләмәс. Ул сезнең күңелләрегезгә (калебләрегезгә) һәм кылган гамәлләрегезгә карый»*, – дигән (Табарани).

Икенче хәдис-шәрифтә болай диелгән: “*Белегез: кеше тәнендә бер ит кисәге бар, әгәр ул сәламәт булса – бөтен тән сәламәт булыр, әгәр ул авыру булса – бөтен тән авыру булыр. Белегез ки, ул ит кисәге – калебтер*” (Бохари, Мөслим).

Бу хәдисләрдән күренгәнчә, динебез калебкә зур әһәмият биреп, аңа игътибарлы булырга боера. Һәр мөселман үз калебенә хуҗа булырга тиеш. Калебләребезне сафландыру – һәрбер мөселманның изге бурычы. Калебләрне өч төргә бүләргә мөмкин.

Беренчесе – иман белән нурланган калебләр. Алар – Аллаһыга һәм Аның Рәсүле Мөхәммәд галәйһиссәламгә бәйләнгән, ислам шәригатенә буйсынган бәхетле калебләр.

Икенчесе – ширек һәм көферлек белән каралган калебләр. Алар – яшәү мәгънәсен аңламаган, бары тик матди, дөньяви ләззәтләргә генә бирелгән бәхетсез калебләр.

Өченчесе – гөнаһ белән пычранган калебләр. Аларга ия булган кешеләр, беренче карашка иман нигезләрен кабул иткән булып күренсә дә, намаз, ураза кебек гыйбадәтләрне вакытында үтәми яисә бөтенләй башкармый. Шундый калебләр исерткеч эчемлекләр куллану, отыш уеннар уйнау, риба, ялган кебек гөнаһларга баткан.

Иң гүзәл калебләр – иман, ислам нуры белән нурланган, күркәм гамәлләр белән бизәлгән һәм һәртөрле гөнаһтан сакланган сөенечле калебләр. Аларга ия булучылар ике дөньяда да бәхеткә ирешәчәк. Шуңа күрә мөселман һәрвакыт һәм һәр урында калебне каралта торган гамәлләрдән ерак торырга тырыша. Киресенчә булса – ул үзен олы куркынычка илтә. Сөекле Пәйгамбәребез саллләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: *“Мөэмин бер гөнаһ эшләгән вакытта аның калебендә бер кара тап барлыкка килә. Әгәр ул тәүбә итеп бу гөнаһтан ваз кичсә – аның калебе пакьләнә. Әгәр ул тәүбә итмәсә һәм гөнаһлы гамәлне кылуны дәвам итсә, аның калебендә кара таплар саны арта һәм аның калебе карала”* (Ибн Маҗәһ).

Түбәндәге аятьләрне истән чыгармыйк: ***“Җанын пакь тоткан кеше морадына (сәгадәткә) ирешәчәк. Вөҗданын кер каплаган кеше, әлбәттә, хәтәр зыян күрәчәк”*** (*“Шәмес” сүрәсе, 9-10 нчы аятьләр*). ***«Мәгълүмдер ки, Аллаһы турында уйлаганда, Аны зикер иткәндә күңелләр рәхәт тынычлыкка ирешә»*** (*“Рәгыд” сүрәсе, 28 нче аять*). ***“Ул Көнне мал да, угыллар да файда китермәс. Әмма Аллаһыга саф күңел белән инанганнар бәхетле булыр”*** (*“Шөгарә” сүрәсе, 88-89 нчы аятьләр*).

**Аллаһны чын күңелдән сөйгән кеше корбанны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалып, гаиләсен, килгән кунакларын һәм күршеләрен, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне хөрмәт итә, аларның күңелләрен күтәрә. Шулай итеп, ул Аллаһның ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кыла**

Мөхтәрәм мөселманнар! Шуны һәрвакыт истә тотыйк, изге гамәлләребез Аллаһы тарафыннан кабул булсын өчен калебләребез иманнан башка ихласлык белән дә бизәкләнгән булырга тиеш. Күпсанлы изге гамәлләрне ихлассызлык белән үтәүгә караганда, аз санлы гамәлләрне ихласлык белән кылу күпкә яхшырак.

Адәм балаларының <u>өченче вазыйфасы</u> – гаиләсе, ата-анасы, туган-тумачалары хакындагы вазыйфасы. Гаилә турында шуны әйтергә кирәк: бөек динебез аның һәрбер әгъзасына күп кенә вазыйфалар йөкләгән. Гаиләнең һәр әгъзасы үз вазыйфаларын төгәл үтәсә, шул вакытта гаилә нык булачак, шуңа күрә шул вазыйфаларны белү генә җитми, аларны җиренә җиткереп үтәргә дә кирәк. Ул вазыйфалар түбәндәгеләр:

– гаилә башлыгы буларак, ир кеше бәхетен һәм сөенечен үз гаиләсендә генә эзләргә, башка гаилә әгъзаларыннан җитдирәк һәм төплерәк булырга, үз гаиләсен кирәк нәрсәләр белән тәэмин итәргә һәм ислам буенча яшәргә бөтен шартлар тудырырга тиеш;

хатын-кыз, иң беренче чиратта, иренә карата булган вазыйфаларны үтәргә тырышырга, аны үз мәхәббәте, йомшаклыгы, игътибары белән бүләкләргә һәм, әлбәттә, гаиләнең намусын һәм шәрәфен сакларга тиеш;

ир һәм хатын якты чырайлы, тәмле телле, бер-берсен аңлап, хөрмәт итеп яшәргә, гаилә серләрен тышка чыгармаска, ниндидер аңлашылмаучанлык, каршылык килеп чыкса – бер-берсенә юл куярга, кирелек күрсәтмәскә тиеш;

ата-ана үз балалары өчен күркәм үрнәк булырга, аларның матди һәм рухи ихтыяҗларын кәнәгатьләндерергә тиеш. Алар һәрбер балага гадел булырга, аларны начар дуслардан, хәрам гамәлләрдән сакларга, яхшы белем һәм тәрбия бирергә, киләчәктә үзләренә күркәм холыклы тормыш иптәшләрен табарга ярдәм итәргә тиеш;

балалар, үз чиратында, әти-әниләрен хөрмәт итәргә, тел белән дә, гамәлләре белән дә рәнҗетмәскә һәм үлемнәреннән соң да онытмыйча, алар өчен дога кылып торырга тиеш.

Алда әйтелгән кагыйдәләр буенча яшәгән гаилә, иншә Аллаһ, нык, сәламәт һәм бәхетле булачак.

Туган-тумачаларыбыз – безнең өчен ата-аналарыбыздан соң иң якын кешеләр, шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле булырга тырышыйк. Алар хакында сөекле Пәйгамбәребез саллләллаһу галәйһи вә сәлләм: *“Ризыгы киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен”*, – дигән (Бохари, Мөслим).

Газиз дин кардәшләрем! Вәгазем ахырында сезне бер риваять белән таныштырып үтәсем килә.

Бөек галим Җүнәйд Багдадига (Аллаһы Тәгалә аны Үзенең рәхмәтеннән аермаса иде) җиде яшь булганда, абыйсы Сарий Сакати аны үзе белән хаҗ гыйбадәте кылырга алып барган. Хәрам мәчете эчендә, ягъни Кәгъбәтулла янында төрле мәсьәләләр буенча сөйләшүләр барган, шуларның берсе шөкрана кылу турында булган. Анда катнашкан һәр шәех бу турыда үз белем-тәҗрибәләре белән уртаклашкан. Сарий Сакати Җүнәйдкә борылып, аңа шөкрана турында үз фикерен белдертергә кушкан. Бераз уйлагач, җиде яшьлек Җүнәйд түбәндәгечә гаҗәеп матур җавап биргән: “Шөкрана кылу ул – Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы булмау, Аның нигъмәтләрен файдаланып, шулар белән гөнаһ кылмау”.

Мөхтәрәм җәмәгать! Бу җаваптан күренгәнчә, Аллаһыга шөкрана кылу, Аңа рәхмәт әйтү – намаз уку, ураза тоту, Коръән уку кебек гыйбадәтләр белән генә чикләнми. Без Аллаһы Раббыбыз биргән әгъзаларыбыз белән дә гөнаһ эшләмәскә тиеш. Күзебезне хәрам булган нәрсәләрдән, телебезне – гайбәттән, ялганнан, яла ягудан, буш сүзләрдән саклыйк. Телләребез белән күбрәк Аллаһыны искә алыйк, файдалы, дөрес сүзләр сөйлик. Карынбызны хәрам ризыклардан, кулларыбызны хәрам гамәлләрдән, аякларыбызны Аллаһының ачуын китерә торган җирләргә барудан саклыйк. Хәдис-шәрифтә болай диелгән: *“Файдасыз эшләрдән качу – яхшы мөселманның билгесе”* (Тирмизи).

Аллаһы Тәгалә барчабызга да ихлас шөкрана кылучылардан булырга, күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалынachак корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт томышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде.

**Вәгазьне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт САБИРОВ әзерләде**

# Корбан гаете хөтбәсенең укылышы

## Беренче хөтбә

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр үә лилләһил-хәмд. Субхәәнә мәң тәкаддәсә зәәтүһүү ганиш-ширки үәззәүәәл. Үә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәлләәли үәл-җәмәәл.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмд. Субхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи зәәтиһил-гукуулү үәл-әфһәәм, үә гәҗәзә гән идраки сыйфәәтиһирраасихуунәл-әгъләәм.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмд. Субхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүәминиинә бишшүһүүри үәл-әййәәмил-фисааль. Үә әүҗәбә фии һәәзиһил-әййәәми галәл-әгънийәәәилхәҗҗә үәт-таүәәфә бил-бәйтил-мукәррами гыйндәл-кәбийрил-мүтәгәәль.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмд. Нәхмәдуллааһәл-ләзии ләм йәттәхыйз саахибәтәү-үә ләә үәләдә, үә ләм йәкүлләһү шәриикүн фил-мүлки, үә ләм йәкүлләһү үәлиййүм-минәз-зулли үә кәббирһү тәкбииraa. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Үә әшһәдү әннә сәййидәнәә Мухәммәдән габдүһүү үә расүулүһүү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәәи би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгәәль. Салләллааһү тәгаалә үә сәлләмә галәйһи үә галәә әәлиһии үә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый үә әтъйәбил-әхвәәл.

Әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәзәә йәүмүн шәриифү үә гыйдүл ләтыйифүл лил-хаүәәссый үәл-гаүәәмм. Йәүмүн газыймүң кадрүһүү лил-әнәәм. Газзыймүү һәәзәл йәүмә бил-ингәәми үәлихсәәни үә иисаалил-әрхәәм. Үә иннәллааһә тәбәәракә үә тәгаалә әүҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи "Үәнхәрь". Үә әмәра халиилиһү би зәбхи үәләдиһил-әшһәри үә үфдийә би кәбшим-минәл-җәннәти би үәәсыйтатил-мәләкил-мукарраб, үә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулилмүгътәбәр. Әл-будһәтү гәң сәбгәтин үәддаьну үәл-мәгзү гән үәәхидин муҗзиәтү үә ләә йәҗүүзул-гаҗфәәә-у үәл-гаръҗәәәъү үә мәкъттуугатүл-үзүни үәл-илйәти үәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гыйндәл-мәзһәбил-мүгътәбәр.

Дахһүү гән әтъйәби әмүәәликүм үә газзыймүүһәә мтисәәлән лиәмри расүулилләәһил-мукаррар. Кәмәә каалә расүулүллааһи салләллаһү галәйһи үә сәлләм: "Газзыймүү дахәәйәәкүм фә иннәһәә галәс-сыйраати мәтаайәәкүм". Үә иннәллааһә тәгаалә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гакыйбәл-фәрьды миң фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһии "Үәзкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт". Әгүүзү билләәһи минә шәйтаанирраҗиим: Йәә әййүһәлләзиинә әәмәнүттәкуллааһә үәлтәнҙур нәфсүм-мәә каддәмәт лигаад. Үәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимә тәгъмәлүн. Бәракә Ллаһу ләнә үә ләкум фил-Куръәнилгазыйм, үә нәфәганәә үә ийәкум биләәйәәти үәз-зикрилхәкиими үә әстәгъфирулләһәл-гаффәәра лии үә ләкүм үә лисәәири җәмәәгатил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһүү һүәл-гафуурур-рахиимул-җәүәәдүл-кәриимүссәмиигуль-галиим.

## Икенче хөтбә

Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһүү үә нәстәгыйинүһүү үә нәстәгъфирүһүү үә нүъминү биһии үә нәтәүәккәлү галәйһи үә нәгүүзү билләәһи миң шүрүури әнфүсинәә үә миң сәййиәәти әгъмәәлинәә мәй-йәһдиһи Ллааһү фәләә мүдыйллә ләһүү үә мәй-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ үә әшһәдү әннә Мухәммәдән габдүһүү үә расүулүһ. Иннәллааһә үә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбиййии. Йәә әййүһәлләзиинә әәмәнү саллүү галәйһи үә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли галәә Мухәммәди үә галәә әәли Мухәммәд бигадәди мәң салләә үә саам. Аллаһүммә салли галәә Мухәммәди үә галәә әәли Мухәммәд бигадәди мән кагадә үә каам, саллии үә сәллим галәйһи үә галәә җәмиигыйль-әнбийәәи үәл-мүрсәлиин. Үә галәә мәләәикәтикәл-мукаррабиинә үә галәә әһли таагәтикә әҗмәгыйн мин әһлис-сәмәәүәәти үәл-әрадыйин. Үәрхәмнәә үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмүъминиинә үәл-мүъминәәт, үәл-мүслимиинә, үәлмүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм үәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә муҗиибүд-дәгаүәәт үә мүнзилүл-бәракәәт, үә раафигуддәраҗәәт, үә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин. Аллаһүммәр-хәмил хуләфәәә-әр-раашидиин үәл-үмәрааа-әл-мәдыйнәл-ләзиинә кадау билхәккый үә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиин үәһди мән һәзәләддиин. Гыйбәәдәллааһ, иннәллааһә йәәмүрү бил-гадли үәл-ихсәәни үә ийтәәәи зил-курбәә үә йәнһәә ганилфәхшәәәи үәл-мүнкәр үәл-бәгъйи йәгыйизукүм ләгалләкүм тәзәккәрүүн. Үзкүруллааһәл-галиййәл-газыймәлкәййәл-каййүүм, йәзкүркүм үәшкүрүүһү йәзидкүм, үәстәгъфирүүһү йәгъфир ләкүм үә ләзикруллааһи тәбәәракә үә тәгаалә әгъләә үә әүләә үә әгаззү үә әҗәллү үә әгъзаму үә әтәмму үә әкбәр.

# Корбан гаете хөтбәсенең тәрҗемәсе

## Беренче хөтбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлуклар дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле зат булганына) акыл ияләре хайран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында ширкәте булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка берниндиилаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул – бердәнбер, аның тиңдәше юк, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Аның колы һәм Рәсүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез – хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Корбанны "Корбан чал!" дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек җиде кешедән һәм бәрән вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз һәм Аллаһы Рәсүленең әмеренә буйсынып корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының рәсүле галәйһиссәлам әйткән: "Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр". Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир-тәшрикъне Гарәфәт көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрикъ көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: "Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз", – дигән. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһыга сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Коръәндә әйтә: "Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсәәзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар" ("Хәшер" сүрәсе, 18 нче аять).

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, Аллаһы каршында истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) – Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хөтбә

Аллаһыга мактау булсын, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңатаянабыз.Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыгынабыз. Кемгә Аллаһы һидаят бирсә – аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса – аңа беркем дә һидаят бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм хак илчесе булуына гуаһлык бирәм.

"Шик юктыр ки, Аллаһы та, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез".

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәре салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәре салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (рәсүлләргә), якын булган фәрештәләренә, шулай ук күкләрдә һәм җирләрдә яшәүче Синә итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син догаларны кабул итүче, бәрәкәт иңдерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидәят бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, олуг, тере, уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләне зикер итү исә – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәлалләтле, иң бөек, иң камил, иң зур гамәл.

# Корбан гаете – хаҗ тәмамлануын билгеләгән мөбарәк ислам бәйрәме

Корбан бәйрәме зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә үткәрелә.

Аллаһы Тәгалә ике пәйгамбәрне зур сынау белән сыный. Ибраһим пәйгамбәр улы Исмәгыйльне корбан итәргә алып барганда, Аллаһның рәхмәтеннән сөрелгән шайтан аңа килеп вәсвәсә кыла. "Сине әтиең үтерергә алып бара. Кач, тизрәк", – ди. Сөекле әти-әнисенең һәм Раббысының сүзеннән чыгарга ияләшмәгән бала: "Мин Аллаһ әмеренә каршы килмим. Әтием барын да белеп эшли", – дип, мәлгуньне ташлар атып куып җибәрә.

Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәте белән Исмәгыйльне саклап кала. Ата кешегә корбан итәргә дип, Аллаһ тарафыннан куй бирелә. Шул көннәрдән бирле, изге бер йола итеп, Корбан гаете билгеләп үтелә.

Корбан бәйрәме ир кешеләргә госел алып, чиста-пакь киемнәрне киеп, мәчеткә гает намазын уку өчен бару белән башлана. Гадәт буенча, мәчеткә барганда тәкъбир – «Аллааһү әкбәру, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр үә лилләһилхәмд» (Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ бөек! Аллаһ бөек һәм Аллаһка мактаулар булсын!) сүзләре әйтелә. Гает намазыннан соң корбан чалына. Аннан соң туганнарны, танышларны зиярәт кылу, табыннар әзерләү, бүләкләр тарату кабул ителгән.

Быел Корбан бәйрәме 24 сентябрьгә туры килә. Татарстанның барлык мәчетләрендә бәйрәм намазы кояш чыгу вакытыннан соң ярты сәгать узгач укыла.

24 сентябрьдә Казанда кояш 5 сәгать 31 минутта чыга, бәйрәм намазы сәгать 6.00 дә башлана.



**Корбан чалу хөкемнәре һәм үтәлергә тиешле шартлар**

* Байлыгы һәм мөмкинлеге булган һәр мөселман өчен корбан чалу ваҗиб (тиешле) гамәл санала. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә Казыйлар һәм Голәмалар шурасы әгъзалары быел нисаб күләме 17 мең дип килештеләр. Гаиләдә артык 17 мең сум акча булганда, корбан чалу мәҗбүри санала.

* Бу эшкә тотынган кешенең үз акылында, балигъ яшендә булуы, сәфәрдә булмавы шарт. Әгәр дә инде мөмкинлеге чикле икән, гөнаһ юк.

* Һәр гамәлдә ният мөһим. Корбан чалу бары бер ният – Аллаһы ризалыгы өчен дип башкарыла.

**Корбанга чалына торган хайваннар**

Сарык, кәҗә, сыер, үгез, буйвол, дөя. Калган хайваннар корбанга ярамый. Корбанлык хайванның кайсы җенестән булуы мөһим түгел. Нигездә, сарык яисә кәҗә сую хуплана. Алар бер еллык булырга тиеш. Әгәр дә сарык ярты еллык, әмма күр һәм таза, бер еллык кебек икән, андый да ярый. Эре мөгезле хайваннар 2 яшьлек, ә дөя 5 яшьлек булырга тиеш.

Эре мөгезле хайван, дөя бер кешедән дә, 7 кешедән дә чалына ала. Бергәләп эре хайванны чалырга теләгән кешеләрнең нияте Аллаһ ризалыгы өчен генә булырга тиеш. Әгәр дә араларыннан берсе ит алырга теләгәннән генә чалса, берсенең дә корбаны кабул ителми.

**Корбанга дигән хайванның кимчелекләрсез булуы яхшы**

Корбан чалырга зыян китерә торган кимчелекләр:

- бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр;
- аксаклыгы берәр урынга барып җитәр өчен комачау итә;
- бер яки ике колагы да тулысынча киселгән;
- күпчелек тешләре юк;
- бер яки ике мөгезе төптән сынган;
- койрыкның ярты өлешенә яки аннан да күбрәгенә зыян килгән;
- имчәкләре юк;
- бик талчыккан хәлдә яки хәлсез;
- тумыштан колаксыз яки койрыксыз;
- көтүдәге калган хайваннарга кушыла алмаслык дәрәҗәдә котырынган;
- нәҗес (чиста булмаган ризык) белән даими тукланган.

**Корбан чалу рәвеше**

Башта тыныч кына корбанны чалынасы урынга илтеп җиткерергә кирәк. Аннары газап кылмыйча, сул ягына яткырасы һәм башын кыйблага борып куясы. Вак мөгезле хайванның арткы уң аягыннан кала өч аягы да бәйләнә. Чаласы кеше ниятен әйтә (мәсәлән, ошбу корбанны фәлән-фәлән улыннан яки фәлән-фәлән кызыннан Аллаһ ризалыгы өчен чалырга ниятлим), янәшәдәгеләр тәкбир әйтә. Шуннан "Әл-Әнгам" сүрәсенең бер өлеше укыла (162-163нче аятьләр): "Әгузу билләһи минәш-шәйтанирраҗим. Бисмилләһи-рахмәнир-рахим. Кул иннә саләти вә нусуки вә мәхъйә вә мәмәти лилләһи Раббил галәмин…" ("Әйт: "Дөреслектә, минем намазым, гыйбадәтем Аллаһка, яшәвем дә, үлемем дә Галәмнәрнең Раббысы ихтыярында, Аңа тиңдәшләр юк"). Моннан соң: "Бисмилләһ Әллаһү әкбәр", – дип хайван чалына һәм дога кылына.

**Корбан итен тарату тәртибе**

Итне өч өлешкә бүлү яхшы. Бер өлеше күршеләргә һәм туганнарга таратыла, икенчесе ярлыларга һәм мескеннәргә, ә өченче өлеше корбан чалдыручының гаиләсендә кала.

**Корбан чалу хикмәте һәм файдасы**

* Корбан чалу Аллаһка якынайта һәм Аның ризалыгына ирешергә ярдәм итә. Раббыбыз корбанга мохтаҗ түгел. Ул моның белән безнең Үзенә якынлык дәрәҗәсен тикшерә. Коръәндә язылган: "Сез чалган хайваннарның итләре, каннары Аллаһка ирешмәс, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз һәм изге гамәлләрегез генә ирешер" ("Хаҗ" сүрәсе, 37нче аять). Шулай ук корбан Исмәгыйль галәйһиссәләм кыйссасын искә төшерә, аның коткарылуы хакында фикерләвебезне яңарта.

* Мөселманнарның корбан чалуы аларның Аллаһ юлында малларын кызганмавын күрсәтә. Бу канун мескеннәрне һәм ятимнәрне шатландыруга китерә, мескен, ятимнәрне сөендерәп, без аларның канәгатьләнүенә ирешәбез.

**ТР МДН дәгъвәт бүлеге**

## Хәзрәткә соравым бар

**"Дин вә мәгыйшәт" газетасының узган санында: "Казыйлар һәм Голәмалар шурасы әгъзалары корбан нисабы күләме буенча бер фикергә килде, гаиләдә артык 17 мең сум акча булганда корбан чалу ваҗиб (мәҗбүри)", - дип язып чыктыгыз. Мин үзем өлкән яшьтәге кеше, мәдрәсәдә укыдым, казыйлар һәм голәмалар фикере белән килешмим. Чөнки күп кенә чыганаклардан "корбан чалу зәкят нисабы булган кеше өчен генә ваҗиб" дип укыганым бар. Үземнең үлемтеккә дип җыйган бераз акчам бар-барын, шул акчадан корбан чалырга тиеш булып чыгаммы?"**



**Мөслимә ханымның соравына Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт САБИРОВ җавап бирә:**

Хөрмәтле укучыбыз! Сезгә Аллаһның чиксез сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын. Корбан чалу фитыр зәкяте нисабы булган кеше өчен генә ваҗиб, ягъни көндәлек тормышта кирәк булган әйберләрдән тыш, көмеш нисабы кадәр малы булган кешегә корбан чалу тиешле. Быел бу нисаб 17 мең сумга туры килә. Әгәр кешенең артык 17 мең акчасы юк икән, аңа корбан чалу ваҗиб түгел. Сезнең үлемтеккә дип җыйган бераз акчагыз көндәлек тормышта кирәк булган әйберләргә керә. Димәк, сезгә корбан чалу мәҗбүри түгел. Чалсагыз саваплы буласыз, чалмасагыз, гөнаһлы булмыйсыз. Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызны Үзенең чиксез рәхмәтеннән аермаса иде.

## Казанда корбан махсус урыннарда чалына

***Корбан чалулар бәйрәм намазыннан соң махсус урыннарда башкарыла, 3 көн дәвам итә. Казан шәһәрендә корбан чалдыру өчен түбәндәге мәчетләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин:***

**ВАХИТОВ РАЙОНЫ:** Мәрҗани мәчете (293-36-86; 249-56-32), Кабан арты мәчете (8-917-248-15-70);

**ИДЕЛ БУЕ РАЙОНЫ:** Ризван мәчете (224-38-47), Тынычлык бистәсендәге Тынычлык мәчете (8-937-613-51-37);

**ЯҢА САВИН РАЙОНЫ:** Казан нуры мәчете (523-16-65; 523-16-56; 523-27-25);

**МӘСКӘҮ РАЙОНЫ:** Сөләйман мәчете (512-03-77; 240-77-11);

**КИРОВ РАЙОНЫ:** Ярдәм мәчете (223-03-59; 240-77-11), Рамазан мәчете (544-56-83; 249-47-52), Юдино бистәсенең Җомга мәчете (8-937-771-88-90);

**СОВЕТ РАЙОНЫ:** Бистә нуры Габделгалләм мәчете (8-927-434-80-93), Иман нуры мәчете (234-84-07; 297-07-32; 296-32-89), Дәрвишләр бистәсенең Ислам мәчете (234-65-23; 8-927-413-33-74), Дин Ислам мәчете (262-30-88; 253-59-34; 8-903-305-59-34), Вознесение бистәсенең Билал мәчете (8-927-415-86-99), Азино микрорайонындагы Гаилә мәчете (8-843-223-06-62).

# “Татарның рухи дөньясы түгәрәкләнде”

## XI Казан халыкара мөселман киносы фестивалендә Татарстан фильмнары барлык биш номинациядә дә катнашты

**Сентябрь башында башкалабызда XI Казан халыкара мөселман киносы фестивале узды. 7 көн дәвамында 7 мәйданчыкта 53 илдән 150 фильм күрсәтелде. Фестиваль кысаларында фильмнарны 20 меңнән артык кеше карады. Кинокартиналарга режиссер Владимир Меньшов рәислегендәге жюри бәя бирде.**





Фестивальнең ябылу тантанасында “Кыска метражлы уен фильмы” номинациясе җиңүчесен режиссер һәм жюри әгъзасы Рәшит Ногманов атады. Конкурска сайлап алынган иң яхшы фильмнар арасында бу номинациядә Салават Юзеев төшергән “Ишекне шапылдатып ябып чыгып китте” (“Хлопнул дверью и ушел”) кинокартинасына тиңнәр табылмады. Әлеге фильм “Иң яхшы ир-ат роле” номинациясендә тагын бер җиңү китерде. Бүләк Илдус Габдрахмановка тәтеде.



“Кыска метражлы документаль фильм” номинациясендә җиңүчене Илдар Ягъфаров бүләкләде. Әлеге номинациядә “Василий Ерошенко. Дорога к солнцу” (Россия) кинокартинасы иң яхшысы дип табылды.

“Иң яхшы документаль фильм” номинациясендә “Война непрощенных” (Россия) фильмы бүләкләнде.

Тантана кунагы актер Семен Стругачев Казанда беренче генә булмавын, әмма моңа кадәр кала белән танышырга өлгермәвен ассызыклады. “Мин үзем өчен яңа, мәдәнияте ягыннан Санкт-Петербургны да уздырган шәһәр ачтым”, – дип, ул фестивальгә озын гомер теләде. “Иң яхшы анимацион фильм” номинациясендә җиңгән “Когда я была ребенком” (Иран) мультфильмы бүләген дә ул тапшырды.

“Яшь Россия” (“Россия молодая”) номинациясендә җиңүче “Ближе чем кажется” киноальманахы режиссерлык төркеменә бүләкне режиссер һәм продюсер Алексей Барыкин тапшырды.

“ТӨРКСОЙ” оешмасының махсус бүләген ТР Мәдәният министрлыгының әлеге оешмадагы вәкиле Лилия Саттарова житкерде. Бүләккә “Рудольф Нуриев. Рудик” фильмы лаек булды. Аны Татарстан режиссеры Фәрит Дәүләтшин төшергән.

“Родина” кинотеатрында киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителеп, тамашачылар арасында зур кызыксыну уяткан, Габдрахман Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романына нигезләнеп төшерелгән шул исемдәге фильм да бүләксез калмады. “Татар әдәбияты классикасын экранлаштыруда өлеш керткән өчен” бүләген ТР парламентының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев кулыннан “Яңа гасыр” ТРКсы генераль продюсеры Миләүшә Айтуганова кабул итеп алды. “Безнең әдәбиятыбыз да, музыка, рәсем сәнгатебез дә бик бай, әмма бүгенге көнгә кадәр кино сәнгатебез дөньяга чыгарырлык дәрәҗәдә түгел иде, һәм менә, ниһаять, бөтен халык мәхәббәтен яулаган фильмнарыбыз барлыкка килә башлады. Димәк, татарның рухи дөньясы түгәрәкләнде дигән сүз”, - диде Разил Вәлиев.





Фестиваль жюриеның махсус бүләгенә Таҗикстанның “Белый воробушек” фильмы һәм Башкортстанның “Ни пуха, ни пера!” анимацион мультфильмы лаек дип табылды.

Казан мэры Илсур Метшин бүләге исә “Под знаком любви. Композитор София Губайдуллина в Казани” кинокартинасы авторларына бирелде.

“Иң яхшы оператор эше” номинациясе дипломы Һиндстанга китте: номинациядә “Имена неизвестны” кинокартинасы җиңде.

“Побег из Москвабада” фильмында төшкән Мария Машкова “Иң яхшы хатын-кыз роле” номинациясендә җиңүче дип табылды.

“Уен киносының иң яхшы сценарие” номинациясендә “Лицо в пепле” (Гыйрак) һәм “Учитель” (Таҗикстан) кинокартиналары сценарийларына фестивальдә тиңнәр булмады.

“Иң яхшы режиссер эше” номинациясендә Ираннан “Без границ” фильмы режиссеры Әмирхөсәен Әзһәри җиңеп чыкты. Аңа бүләкне ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин тапшырды һәм оештыручыларга, әлеге фестивальне беренче тапкыр уздыручыларга, фильмнарны конкурс өчен сайлап алучыларга, форумның жюри әгъзаларына, тамашачыларга рәхмәт белдерде.

Фестивальнең төп призы быел Кыргызстанга китте. “Иң яхшы уен фильмы” номинациясендә “Курманжан Датка” (“Королева гор”) картинасы җиңде. Бүләкне жюри рәисе Владимир Меньшов тапшырды.

ТР парламенты рәисе урынбасары Римма Ратникова тамаша залында утыручыларны бәйрәм белән котлап, республика җитәкчелеге исеменнән сәламләде. “Бу фестивальгә мөселман дөньясында ихтыяҗ бар, һәм ислам мәдәнияте белән кызыксынучылар аны ярата. Ул кешеләргә бер-берсен аңларга, тынычлыкта яшәргә ярдәм итәр дип ышанам. Фильмнарның сыйфаты, катнашучылар географиясе белән мөнбәребез тагын да югарырак күтәрелде. Безнең фильмнар да фестивальдә катнашып кына калмады, бүләкләр дә яулады. Бу фестивальгә тагын да зуррак биеклекләр насыйп булсын”, - дип, Римма Ратникова ТР Президентының махсус бүләген тапшырды. Аңа Мисыр, Франция, Норвегиянең уртак җимеше – “Прошлое вернется” фильмы лаек булды.

# Кыртапа халкының шатлыгын мөфти хәзрәт тә уртаклашты



**ТАТАРСТАН** мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Кама Тамагына эшлекле сәфәр кылып, район башлыгы Павел Лоханов белән очрашты. Очрашуда мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, район имаммөхтәсибе Галимулла хәзрәт Яруллин да катнашты. Җитәкчеләр хакимият вәкилләре белән дин әһелләре арасындагы хезмәттәшлек турында сөйләшкәннән соң, мәхәллә халкы белән бергә Кыртапа авылында төзелгән Тәлгать мәчетен ачу бәйрәмендә катнаштылар. Әлеге күркәм чарада Камил хәзрәт мәхәллә халкын яңа мәчетле булулары белән тәбрикләде, үгет-нәсыйхәт сүзләрен җиткерде, Аллаһы Тәгаләдән авылга, биредә яшәүчеләргә бәрәкәт сорады, динле булуларын теләде.

Тәлгать мәчете - районда төзелгән 27 нче иман йорты.

Мөфти хәзрәтләре Сөйки авылында да булды. Ул биредә 2012 елның 10 июнендә "Булгария" теплоходы баткан урын каршында төзелгән мәчеттә мәрхүмнәр рухына дога кылды.

# Комлы Кавал мәчетле булды

**ЛАЕШ** районы Комлы Кавал авылында Салих дип исемләнгән мәчет ачылды. Яңа иман йорты ачылышында мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Лаеш районы имаммөхтәсибе Рәфкать Гатауллин, Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Михаил Фадеев, авыл халкы һәм башка чакырылган кунаклар катнашты.

Рөстәм хәзрәт Хәйруллин Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламнәрен тапшырды. Ул мәчет төзелешенә зур өлеш кертүче "КазаньСтройКонсорциум" оешмасы җитәкчесе Фәрит Сафинга нәзарәтнең рәхмәтләрен җиткерде һәм махсус хат тапшырды, яңа мәчет имамы Рәшит хәзрәт Туктамышевка җирлектә дини эшчәнлек алып баруда уңышлар теләде.

Район башкарма комитеты җитәкчесе Михаил Фадеев сүзләренчә, мәчет районда 21 нче булып ачылды һәм тагы өч мәчет төзелеп килә. Салих мәчете бер ел эчендә сафка баскан. Төп бинадан тыш, биредә балалар өчен махсус мәйданчык, махсус тәһарәт алу бинасы да каралган.



# Азнакай мөхтәсибәте район мәчетләре календарен ясаган

**АЗНАКАЙ** мөхтәсибәтенең 44 мәчете фотосы төшкән стена календаре дөнья күрде. "Әлеге календарьга без барлык мәчетләребезне дә керттек,- ди имам-мөхтәсиб Азат хәзрәт Талибуллин , - анда шәһәребезнең Ак мәчете, Зәңгәр мәчете, Азнакай нуры мәчете, авылларда һәм Актүбә бистәсендә эшләп килүче мәчетләрнең фотолары урын алды".

Хәзерге вакытта барлык мәчетләрдә дә имам Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча вәгазьләр укыла, көндәлек һәм җомга намазлары үткәрелә, районның 20 мәчетендә ислам дине нигезләрен һәм Коръән укырга өйрәтү дәресләре оештырылган. Ел саен 7 мәчеттә мәктәп яшендәге балалар өчен ял итү лагерьлары үтә. Район имамнары өчен атна саен үзәк мәчеттә укулар алып барыла. Соңгы елларда мәчетләрне төзү һәм яңарту буенча район башлыгы Марсель Шәйдуллин инициативасы белән дә бик күп эш башкарылды.

"Азнакай районы мәчетләре төшкән 2016 ел календаре 1989 - 2015 елларда эшләгән имамнарның эшенә нәтиҗә булды. Әлеге календарь азнакайлыларга бик яхшы бүләк булыр дип уйлыйм", - ди Азат хәзрәт.

# Чирмешән хастаханәсендә дога белән дәвалыйлар

Дин тотучылар өчен Чирмешән хастаханәсендә гыйбадәт кылу бүлмәләре ачылды. Алар стационарның өченче катындагы ашханә янәшәсендә урнашкан.

Терапия бүлегендә дәваланучы Фәһимә апа Закирова яңа бүлмәдә өйлә намазы укып чыккан. Бүлмәдән иман нуры балкып тора дип, шатлана ул.

- Авырып китсәк, Аллаһны тагын да ешрак искә төшерәбез бит. Хастаханәдә яткан вакытларда болай да дини китапларыбызны алып килеп, әчтән генә укый идек, ә бу бүлмәләрдә сиңа беркем дә комачауламый. Урын барыбызга да җитә. Хастаханә җитәкчелегенә рәхмәт, бик әйбәт эшләгәннәр, - ди Валентина Пыжикова да.

Мөселманнар бүлмәсендә идәнгә намазлыклар җәелгән, укысаң, дини китаплар да бар. Христианнар ягында да дини кирәк-яраклар урнаштырганнар, кечкенә генә китапханә дә булачак икән.



# Аксубайда гошер җыялар



**АКСУБАЙ** мөхтәсибәтендә һәм мәхәлләләрдә гошер сәдакасы җыю башланды. Бу эш мохтаҗларга ярдәм итү нияте белән башкарыла.

Һәрбер нәрсәне пакьләүче әйберләр бар. Бакчаларыбызда үсә торган яшелчәләрнең һәм җимешләрнең зәкяте гошер дип атала. Гошер уннан бер дигәнне аңлата, ягъни үстергән бодай, арпа, дөге, бәрәңге, кәбестә уңышының уннан берен мескеннәргә, мохтаҗларга бирергә тиешбез. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Мин биргән нигъмәтләремә шөкер кылсагыз, арттырып бирермен. Әгәр биргән нигъмәтләремә шөкер кылмасагыз, газабым каты булыр".

Бу изге эшкә шулай ук Яшел Үзән, Балтач районы мөхтәсибәтләре дә керешкән.

Мәгълүматлар Dumrt.ru сайтыннан алынды

Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

# Ислам тәрбиясенең кайбер принциплары

**Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди: "Тәхкыйк син күркәм холыктасың"** ("Нун" сүрәсе, 4 нче аять).

Кешене күтәрүче, камиллеккә ирешергә булышучы һәм аны башка җан ияләреннән аерып торучы нигез булып әхлак тора. Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә салләм) әхлакны кешенең тәрбияләнгән сыйфаты дип түгел, ә асылында, табигатендә булырга тиешле сыйфаты дип исәпләгән.

Әдәп һәм әхлакка ислам аерым игътибар бирә. Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә салләм) күп кенә фикерләрендә шуны күрсәтә. Түбәндәге хәдис моңа мисал булып тора: "Камил иман күркәм холыклы кешедә. Арагызда иң яхшы кеше – хатынына яхшы мөнәсәбәттә булучы кеше" (әт-Тирмизи, ибн Хаббәнә).

Мөселманнарда ислам динен таратуда иң яхшы ысул булып яхшы тәрбия һәм күркәм холык торган. Мәсәлән, Малайзия, Индонезия, Бруней кебек илләр ислам динен гарәп диңгез сәяхәтчеләре һәм сәүдәгәрләренең күркәм холыкларына, гаделлекләренә һәм намуслылыкларына карап кабул иткәннәр. Мөселманнарда әхлакның мөһимлеге тарихта аерым шәхесләрнең һәм аерым халыкларның ислам динен кабул итүләренең сәбәбе булып торган.

Исламда күркәм холыкка тырышлык белән үзеңне тәрбияләү рәвешендә ирешәләр. Әр-Руми әйтүенчә, кешене хайваннан аерып торучы төп нәрсә – тәрбия һәм әхлак. Бу максатка ирешер өчен, билгеле этаплар аша үтәргә кирәк. Безнең динебездә хәләл һәм хәрам мәсьәләләренә килгәндә, барлык рөхсәт ителгән һәм тыелган нәрсәләрдә Аллаһы Тәгалә салган хикмәт бар. Тәрбия исә дин буенча эшләнелергә тиешле төп аспект. Коръәни Кәримдә болай диелә: "Ий мөэминнәр, үзегезне һәм өй җәмәгатегезне җәһәннәм утыннан саклагыз, ягъни үзегез шәригать хөкемнәрен дөрес үтәп, җәмәгатьләрегезгә шәригать хөкемнәрен дөрес өйрәтегез, ул утның утыны – кешеләр һәм ташлардыр. Ул җәһәннәмгә билгеләнгән ґазаб фәрештәләре бар, алар җәһәннәм әһеленә каты сүзле, каты куллы ґазаб кылуда бик куәтлеләрдер, алар үзләренә булган боерыкларда Аллаһыга һич хилафлык кылмаслар, Аллаһыдан нинди боерык булса – шуны эшләрләр" ("Тәхрим" сүрәсе, 6 нчы аять).



Исмаил Хаккы Бурсави үзенең танылган "Рух әл-Баян" тәфсирендә бу аятьне болай аңлата: "Гаилә – ул кеше белән рухи бәйләнештә булган яраткан кешеләр. Бәйләнештәге кешеләр аның белән бу дөньяда да, ахирәттә дә бергә булачаклар. Шуңа күрә кешегә үзен җәһәннәм утыннан саклаган кебек, гаиләсен дә уттан сакларга кирәк. Кыямәт көнендә кеше белән бергә аның туганнары һәм дуслары яңадан терелтелү сәбәпле, аларны да, мөмкин булганча, уттан сакларга кирәк. Кеше яратканнары белән бергә терелтеләчәк".

Шулай ук ибн Габбас (радыяллаһу гәнһү) Коръәннең бу аятен түбәндәгечә аңлата: "Аллаһы Тәгаләгә буйсыныгыз. Тыелганнан тыелыгыз. Балаларыгызны тыелганнан ерак торырга һәм Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәргә өндәгез.Чөнки бу балаларыгызны уттан саклаячак" (һидаят әл-Мөршидин).

Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә салләм) болай ди: "Сезнең һәрберегез – көтүче, һәм сез көткәннәрегез өчен җаваплы. Әмир – кешеләрнең көтүчесе һәм үз көтүе өчен җавап тота.

(Ахыры 11 нче биттә.)

# Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) сәхабәләренең әхлагы һәм этикасы

**Аллаһы Тәгаләнең яраткан Пәйгамбәре Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә салләм) болай дигән: "Мин гадел холыкны камил дәрәҗәгә җиткерү өчен җибәрелгән".**

Ислам динендә иман, Аллаһы Тәгаләне төшенү, кешенең башка кешеләргә һәм җан ияләренә мөнәсәбәте һәм башка тормыш аспектлары нинди булырга тиешлеге камил дәрәҗәдә билгеләнгән. Димәк, ислам кешене тормышта кирәк булачак бөтен нәрсәгә дә өйрәткән. Бу бәя биреп бетергесез белемнәрне без Аллаһы Тәгалә Илчесе (саллләллаһу галәйһи вә сәлләм) белән бергә үскән, тәрбияләнгән кешеләрдән алабыз. Алар коры җиргә һәм ташларга утырганнар, өсләрендә хөрмә агачы яфракларыннан ясалган түбә булган. Без Аллаһы Тәгалә Илчесеннән (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) тәрбия алган сәхабәләр сүзләрен игътибар белән тыңлыйбыз.

Сәхабәләр Пәйгамбәребез (саллләллаһу галәйһи вә сәлләм) янында тәрбияләнеп үскәннәр. Кайберәүләре, мәсәлән, Гомәр (радыяллаһу ганһү) кешеләр арасында үзенең гаделлеге белән аерылып торган. Госман (радыяллаһу ганһү) тыйнак һәм оялчан булган. Галине (радыяллаһу ганһү) белем капкасы дип атаганнар. Габбасны (радыяллаһу ганһү) кешеләр зур галим буларак хөрмәт иткәннәр. Ибне Гомәр (радыяллаһу ганһү) дини сорауларны чишкәндә зирәклеге һәм тирән белеме белән аерылып торган. Халид бине Вәлид (радыяллаһу ганһү) бөек гаскәр башлыгы булган. Әбү Һурайраның (радыяллаһу ганһү) иң күп хәдис тапшыручылардан булуы белән билгеле. Сәлмән әл-Фариси (радыяллаһу ганһү) күренекле фикер һәм белем иясе булган. Аллаһы Тәгалә аларның барысыннан да разый булсын.

Бөек шәех Мостафа Исмет Гарибуллаһның "Рисалә Кудсия" китабында әйтелгәнчә, сәхабәләр – Галәмнәр Хуҗасының хәзинәләре. Чыннан да, Аллаһы Тәгалә бу кешеләрнең дәрәҗәләрен күтәргән, алар Пәйгамбәребез (саллләллаһу галәйһи вә сәлләм) тәрбиясендә үскәннәр. Шуңа күрә без алар турында бары тик яхшы фикердә булырга тиеш.

Танылган сәхабәләрнең берсе – Җәрир бине Габдуллаһ әл-Бәҗәли (радыяллаһу ганһү). Бу мәкаләдә аның мисалында мөселманнарның үзара мөнәсәбәтләре нинди булырга тиешлеген күрсәтәсем килә.

Бервакыт Җәрир (радыяллаһу ганһү) үзенең хезмәтчесен базарга ат сатып алырга җибәрә. Хезмәтче базарга бара, сатучы янына килеп, атның бәясен сорый. Башта алар бәядә килешә алмыйлар, соңрак өч йөз дирһәмдә тукталалар. Җәрирнең (радыяллаһу ганһү) хезмәтчесе үзе белән андый акча юклыгын әйтә һәм бергәләп хуҗасы янына барырга тәкъдим итә. Шуннан соң алар Җәрир (радыяллаһу ганһү) янына китәләр. Җәрир (радыяллаһу ганһү) хезмәтчесеннән атның бәясен сорый. Хезмәтче:

- 300 дирһәм, - дип җавап бирә.

Җәрир (радыяллаһу ганһү), кыйммәтрәк бәя ишетергә уйлап, сатучының күзенә карый һәм аннан:

- Син атыңны 500 дирһәмгә сатарга ризамы? - дип сорый.

Сатучы дәшми. Җәрир (радыяллаһу ганһү) дәвам итә:

- Бу ат өчен 600 дирһәм җитәрлек бәя буламы?

Сатучы дәшми, ә моны күзәтеп торучылар гаҗәпкә калалар. Җәрир (радыяллаһу ганһү) бәяне күтәрүен дәвам итә:

- 700 дирһәм?

Сатучы исе китеп Җәриргә (радыяллаһу ганһү) сорау бирә:

- Сез кем? Сатучымы әллә сатып алучымы? Гомеремдә килешенгән бәядән зуррак бәя биргән кешене күргәнем булмады. Әйтегезче, сез бу ат өчен ни сәбәпле мондый бәя түләргә әзер?

Җәрир (радыяллаһу ганһү) аңа җавап бирә:

- Мин Аллаһы Тәгалә Илчесенә (саллләллаһу галәйһи вә сәлләм) ант иткәндә һәр мөселман белән гадел һәм намуслы булырга сүз бирдем. Синең атыңның бәясе – 700 дирһәм. Мин моннан да азрак бәя бирсәм, Пәйгамбәребезгә (саллләллаһу галәйһи вә сәлләм) биргән сүземне бозар идем.

Сәхабәләр тормышыннан хикәяләр бик мөһим, аларны өйрәнергә кирәк, чөнки алар Мөхәммәд (саллләллаһу галәйһи вә сәлләм) Пәйгамбәр өйрәткән күркәм холык, тәрбиялелек, гаделлек һәм намуслылык чагылышы булып тора. Аларның йөрәкләре чиста һәм эчкерсез булу сәбәпле, алар Аллаһы Тәгалә кушканнардан бер адымга да тайпылмаганнар. Сәүдә кебек эшләрдә дә алар үзләренең Аллаһы Тәгалә күзәтүе астында булуларын сизгәннәр. Хөрмәт һәм эчкерсезлек белдереп, сәхабәләр Коръәни Кәримдә күрсәтелгән чикләрдән чыкмаганнар. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә Илчесе (саллләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дигән: "Минем сәхабәләрем йолдызлар кебек: аларның кайсысына иярсәгез дә, дөрес юлдан барачаксыз".

Аллаһы Тәгалә безгә Пәйгамбәребез (саллләллаһу галәйһи вә сәлләм) сөннәте буенча яшәргә язсын һәм безгә моны җиңеләйтсен иде. Әмин.

# Мәрҗани мәчете тарихы: онытылмас исемнәр

*2015 ел - татар дин галимнәре елы дип игълан ителүгә, бу юнәлештә шактый күркәм эшләр башкарылды. Тарихыбызны барлауда бәрәкәтле чаралар күрелә.*

*Дин әһелләребезне искә алып, китап арты китап язучы, милли хәрәкәт активисты Рәүф Ибраһимовның дин тоту эзәрлекләнгән елларда Мәрҗани мәчетендә имамлык иткән Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин хакында саллы гына хатирәләр китабы басылды. Күптән көтелгән әлеге хезмәт зурлап тәкъдир ителде. Хөрмәтле хәзрәтне күреп белгән һәм сугыштан соңгы елларда Мәрҗани мәчетенә йөрүче тарикать әһелләре, корьәнхафизлар белән таныш булган* **Зөбәрҗәт апа МӨХӘММӘТҖАНОВА** *да (ул Казанның соңгы ишаны Гарифулла хәзрәт Гайнуллинның кызы һәм әтисенең дин-ислам юлындагы мирасын галимнәр белән уртаклашучы, берәмтекләп саклаучы) хәтер төпкелләрендә сакланган кадерле истәлекләрен газета укучыларыбызга җиткерергә теләк белдерде.*

*Рухи мирасыбызга аерым бер хөрмәт белән караучы, рухи остазлар хакында тарих өчен кыйммәтле мәгълүматларны киң җәмәгатьчелеккә ирештерү теләге көчле булган Гарифулла кызы Зөбәрҗәт апаның сөйләгәннәрен газета өчен журналист* **Вәсилә РӘХИМОВА** *әзерләде.*

Әлхәмдүлилләһ, гаиләдә алган дини тәрбия, әтиәниемнең икесенең дә зикер ияләре булулары сәбәпле бәрәкәтле дин-ислам мохитендә яшәвем белән бәхетле мин. Әхмәдзәки Сафиуллин хакында яңа гына чыккан истәлекләр китабын кулыма алуга, үземнең дә яшьлегемдә очраткан, аралашкан хөрмәтле затларыбыз, гыйбрәтле шәхесләребез хакында сөйләү теләге туды.

Сугыштан соңгы еллар. Мин 18 яшьлек кыз Казанга килдем, эшкә урнаштым. Кая барырга да юк: ачлык, ялангачлык. Эштән кайтам да, Мәрҗани мәчетенә барам. Намазларымны укыйм, Коръән укыганнарын тыңлыйм. Ул чакта анда Мирза кари Бархиев (1890-1974) имамлык итә иде. Хәзрәт чыгышы белән хәзерге Чүпрәле районы, Шәйморза ягыннан иде. Мәкаме бик яхшы иде. Бик яратып тыңлый идем дә, Галимулла улы Мирза кариның Коръән укуы белән тукланып, шул хәлдә фатирыма кайтып куна идем. Хәзрәт хатыны белән озын, матур гомер кичерде.



**Сугыштан соңгы елларда Мәрҗани мәчетендә имамлык иткән Галимулла улы Мирза кари Бархиев җәмәгате белән. 1970 ел**

Дөммә-дөм сукыр Минһаҗ кари Гайнетдиновны хәтерләүчеләр дә инде бакыйлыкка күчеп баралар. Бик гыйбрәтле язмышлы дин кардәшебезнең тәрҗемәи хәле турындагы язмасын еламыйча укып та булмый: “1891 елда, ачлык елны туганмын. Иманага түләүләр күп булу сәбәпле, әтием Гайнетдин атын да, сыерын да сатып түләргә мәҗбүр булган. Гаиләбез бик тә фәкыйрьлеккә калган. 1893 елны ике яшьтә чәчәк чыгып, сукырайганмын. Безнең Корноух районы Олы Әшнәк авылында иске мәктәп бар иде. Мине өч яшемдә я апа, я абый җилкәсенә салып (аягыма киергә әйбер юк), шул мәктәпкә илтәләр, кичен генә алып кайталар иде. Шулай 7 яшемдә гарәп сүзләрен таный идем инде. Яхшы укый башладым. 11 яшькә җиткәндә укып, авыл мәктәбенең отличный ученигы булдым. 1907 елдан башлап 1915 елга кадәр шул авыл мәктәбендә укытучы булдым. Җәй көннәрендә Казанга килеп укып йөрдем. Кышын шәкертләр укыттым. 1932 елга кадәр башка җирдә укытучылык иттем. Аннан сәламәтлегем китте, ике колагым ишетми торган булды, башым авырта, аякларым туңа торган булып калды. Балаларымны Казанда үстерәсем, белем бирәсем килгәч, 1945 елга кадәр колхозда эшләп, 1 сентябрьдән 4 бала белән Казанга күчендек. Февраль аена кадәр вак балалар белән хатыным Маһибәдәр колхозда эшләде. Миңа пенсия бирүегезне сорыйм...”

Сукыр килеш Коръән ятлаган, кари булган егет Оренбург якларында үскән, дини белемле, бик матур мөнәҗәтләр әйтүче Маһибәдәргә димче җибәргән. Яшь кыз гарип егетнең рәнҗүеннән куркып, ризалык биргән. Маһибәдәр абыстай буйлысынлы, затлы кеше иде. Бер-бер артлы балалары Шафия, Кафия, Факия, Нәҗип, Даниял туган. Нәҗип дигән улы пенсиягә чыккач, Киров районындагы Рамазан мәчетендә имамлык итте, гарип энесе Даниялны бакты.

Сугыштан соңгы авыр елларда таныштым мин бу гаилә белән. Ул чакта Минһаҗ абыйның корьәнхафиз икәнен белүче дә юк. Һәркемнең үз хәле хәл. Мәрҗани мәчетенә якында гына минем туганнан туган апам Вәсимә белән җизнәм Хәким (аны тирә-якта мичче Хәким дип йөртәләр иде) яшиләр иде. Менә шул җизнәм Минһаҗ карины җомгага алып чыга, халыкка таныштырып, “бу сәдака иясе” дип, аның гаиләсенә кешеләрдән ярдәм оештырганы исемдә. Җомгадан соң Минһаҗ карины өйләрендә ашатып-эчертеп, тәрбия күрсәтәләр иде алар. Ул чакта Кабан күлендә көймәләр йөри иде. Кабанның икенче ягында - Спартаковская урамында яшәүче Минһаҗ карины җомгадан соң еш кына көймәгә утыртып, өенә озатkalый идем.

Торып-торып исемнәре хәтердә яңара торган, дин-ислам кушканча яшәүче күпме зыялы кардәшебез белән аралашып яшәдем. Аларның гыйлеменә дә, яшәү рәвешенә дә сокланган, гыйбрәтләнгән вакытларым күп булды. Инде сөйли торган темадан бераз читләшеп, шушы хөрмәтле затларыбызның тәрҗемәи хәлләрендәге соклангыч сыйфатларына игътибарыгызны юнәлтәсем килә. Яңа гына телгә алган Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин 20 еллап Кизләү мәдрәсәсендә белем алган. Бүгенгечә әйтсәк, зур галим булып җитешкән. Буйга-сынга төз, төскә-биткә чибәр егетне туган авылы Норлат районының Колбай-Мораса авылына мулла итеп билгелиләр. Элеккеге мулла яшь булуына карамастан үлгән, ике кызы һәм хатыны калган була. Авыл картлары аңа шул тол калган Зәйнәпне димлиләр.

Мирза кари да төскә-биткә затлы кеше иде. Ул да балалы хатынга өйләнә, мин хафиз дип тәкәбберләнеп тормый. Бу мисаллар нәрсәне күрсәтә? Ул заманнарда хатын-кызларга карата җәмәгатьтә никадәрле кайгырту, хөрмәт булган. Кадерле зат саналганнар алар. Егетләр дә алар алдында җаваплылык сизгәннәр, кайгырту, ярдәм кирәклеген тирән аңлаганнар. Балалы хатыннан хәзерге кебек йөз чөерү булмаган, киресенчә, баласын үстерешергә үзләрендә көч тапканнар, җитди адымга барганнар. Хәзер исә үзләрен ипле генә мөселман дип йөрүчеләр ике тапкыр аерыла, өченче никахына да кыз эзли.

Менә шуларны уйлап, чагыштырып утырам. Күңелемдәгеләр белән уртаклашуны дәвам итеп, сентябрьдә – мөселманнарыбыз көтеп алган зөлхиҗҗәдә хаҗ гыйбадәте кылу хакында да әйтеп, күңелгә һич тә ятмаган күренешләрне искәртәсем, кардәшләремне бу хатадан арындырасым килә. Сүз менә нәрсә турында: узган ел Раббым миңа кабаттан хаҗ кылуны насыйп итте. Гарәфә көнне күп гыйбадәтләр кылып, төнне Мөздәлифәдә ташлар җыеп, Минага кайттык. Гает көне! Билгеле, барысы да арыган, талчыккан. Гает икәнен искә дә алмыйча кайбер хаҗияләр үле-мәле кер уа, бау суза. Аннан бау тарттырылган, моннан бау тарттырылган. Ирләр бер тирәгә җыйналып чәч алышалар. Ибраһим галәйһиссәлам улы Исмәгыйльне чалырга алып килгән җирләрдә,пәйгамбәрләребезнең аяк эзләре сакланган үзәндә ләбаса без! Зур бәйрәмебез – Гает көн! Шушы көннең кадерен белергә, кадерле урында гамәл-гыйбадәттә булырга кирәк бит. Нинди хәл ул Гает көнне баш күтәрми кер юу? Сез дә уйлап, фикер йөртеп карагыз әле, кардәшләрем. Күңелемдә җыелганнарны уртаклашып, сезне күп хаталардан арындырасы килү ниятем.

**Зөбәрҗәт**
**МӨХӘММӘТҖАНОВА**

# Ислам тәрбиясенең кайбер принциплары

**(Ахыры.**
**Башы 10 нче биттә.)**

Ир-ат гаиләсенең көтүчесе, һәм ул гаиләсе өчен җавап тотачак. Хатын-кыз иренең малы (йорты) һәм аның балалары өчен җаваплы. Кол хуҗасының малы өчен җавап тота. Игътибарлы булыгыз! Сезнең һәрберегез – көтүче, һәм һәрберегез үз көтүе өчен җавап бирәчәк” (Мөслим.)

Баласының тәрбиясенә игътибар бирмәүче кеше баласын үз кулы белән утка ташлый. Моның өчен җәза үзенең һәм баласының газаплануы була. Шулай ук тирә-ягындагы җәмгыять тә зыян күрәчәк.

Мәүләнә Җәлаләтдин Руми “Мәснәви” китабында болай яза: “Кешегә әхлаксыз белем бирү залимгә корал бирүгә тиң”. Әхлакның бердәнбер нигезе – дин. Дингә бернинди мөнәсәбәте булмаган кешедә әхлак эзләү – вакытны бушка уздыру. Аның ахыры һичшиксез аянычлы булачак.

Аллаһы Тәгалә Илчесе (саллаллаһу галәйһи вә саллләм) тапшырган әхлак ориентирлары иң яхшы һәм лаеклы булуларын иртәме-соңмы бөтен кешелек аңлаячак.

Белем бирүдә дини-этик нигезләргә игътибар бирмәү - кеше табигатенә каршы бару. Чөнки Аллаһы Тәгалә кешене гайбадәт кылуга мохтаҗ итеп яраткан. Шул сәбәпле баланы диннән башка тәрбияләүне күз алдына китереп булмый. Һәр бала иман белән туа, шуңа күрә иң яхшы тәрбия системасы – дини тәрбия.

Нәкъ менә Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән система булганга күрә, ул үзенең нигезен беркайчан да югалтмаячак. Ислам дөнья ахырына кадәр булачак, ә аның белән бергә ислам тәрбия системасы да.

Аллаһы Тәгалә гөнаһларыбызны кичерсен һәм безгә кешеләрнең иң яхшысы, Аллаһы Тәгаләнең Илчесе, Мөхәммәд Пәйгамбәр (саллаллаһу галәйһи вә саллләм) әхлагы һәм әдәбенә иярү мөмкинлеген бирсен иде. Әмин.

# Дога кабул булсын дисәң ...

**“Дога” сүзе гарәп теленнән “ялвару”, “сорау” дип тәрҗемә ителә, шәригатьтә исә дога ул – Аллаһка мөрәҗәгать итеп, Аннан нәрсәдер өмет итү. “Бәкара” сүрәсенең 186 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә бу хакта болай ди: “Бәндәләрем Минем турында сораштырсалар, әйт: Мин чыннан да һәр кешегә бик якын һәм Миңа ялварып дога кылучыларга җавап бирәм, бәлки алар туры юлны табарлар”.**



Шулай да кайбер кешеләр: “Дога кылабыз, ләкин теләгән нәрсәләргә ирешә алмыйбыз”, - дип зарлана. Дөрестән дә, ни өчен кайбер догалар кабул була, ә кайберләре юк? Моның турында ислам галимнәре нинди фикерләр белдерә? Иң элек шуны әйтергә кирәктер: догаларыбыз кабул булмаса, моңа карап кына Аллаһы Тәгалә юмарт түгел диген нәтиҗә ясарга ярамый, чөнки без сораган нәрсә хәерлегәме-юкмы икәнен Аллаһ яхшырак белә (соңрак кеше моны үзе дә аңлый һәм: “Ярый әле мин теләгәнчә барып чыкмады”, - дип уйлап куя).

Шунысын да онытмаска кирәк: һәр кешенең Аллаһ каршында билгеләнгән бурычлары бар. Шушы бурычлар үтәлмәсә, нишләп догам кабул булмады икән, дип аптырыйсы юк... Алай гына да түгел – Аллаһы Тәгалә безгә йөкләгән фарыз-вәҗибләр (мәҗбүри эшләнергә тиешле гамәлләр) башкарылып барган очракта да дога кабул булуның кайбер мөһим шартлары бар. Шуларның берничәсен искә алып китик:

- дога ул – гыйбадәт, ә һәр гыйбадәт итагатьлек-тәкъвалыкка нигезләнеп, игътибарны туплап, ихлас күңел белән кылынырга тиеш:
- дога кылганда рөхсәт ителгән, хәләл булган нәрсәләрне генә сорарга кирәк (Аллаһ тыйган, ягъни хәрам булган нәрсәне өмет итеп дога кылу катгый тыела). Әйтик, хәзер күпләр ниндидер максатка ирешәм дип процентлы бурыч ала яки киресенчә – процент билгеләп әҗәткә акча бирә, ягъни рибага керешә. Ә ислам дине буенча риба – катгый тыелган хәрам гамәл. Галимнәр аңлатканча, һәр кешенең ризыгы, милке, ул ия булачак әйберләре тәкъдирләнгән һәм үзенә насыйп булганга барыбер ирешәчәк, ә риба белән Аллаһ тәкъдиренә иман китермәгән кешеләр генә шөгыльләнә... Шулай итеп, догаларыбызда “шушы аз процентлы кредитны алырга ярдәм итсәң иде” кебек үтенечләр белән Аллаһка мөрәҗәгать итү ярамый. Коръәндә китерелгән “Раббәнә” догасында Аллаһы Тәгалә Үзенә болай мөрәҗәгать итәргә өйрәтә: “Йә Раббыбыз, безгә бу дөньяда да, ахирәттә дә яхшылык кына бир һәм безне ут газабыннан сакла” (2 : 201);
- кеше авырлык кичергән вакытта Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итсен өчен, ул шатлыклы, тыныч көннәрдә дә Аллаһны онытмаска, гел шөкер кылып яшәргә тиеш;
- дога кабул булсын өчен хәрам ризык ашамаска, хәрам эчемлекләр эчмәскә, хәрам кәсеп белән шөгыльләнмәскә кирәк. Киң таралган күренешне – туйларда, юбилейларда һәм шуның ише башка чараларда хәмер тутырылган рюмкаларны күтәреп теләк теләү гадәтен мисалга китерергә мөмкин. Туганына яки дустына “озын гомер”, “сәламәтлек”, гаилә корган яшь парга “сау-сәламәт, тәртипле (!) балалар” теләп тост әйтүче кеше үзенчә “дога кыла”, чөнки кешенең саулыгы да, гомер озынлыгы да, балалар булу-булмавы да – фәкать Аллаһ кодрәтендә булган нәрсәләр. Әмма аракы эчүне тыйган Аллаһтан шул хәрамны эчкән мәлдә ничек итеп нәрсәдер сорарга мөмкин? Гади мантыйк белән фикерләгәндә дә бу сәер, аңлашылмый торган күренеш... Бер уңайдан шуны да әйтеп китәргә кирәктер: туачак баланың холкы, сәләтләре, башка шәхес хасиятләре белән бәйле булган үзенчәлекләре әтисенең орлыгында чагылыш тапкан нәсел геннары нигезендә формалашса, тәне әнисе карынында үсеп, җыелып, формалашып бетсен өчен “материал” буларак шул әнисе ашаган ризык файдаланыла. Әгәр туачак баланың әтисе аракы эчсә, яхшы геннар да бозылып үзгәрә, әнисе хәрам ризык ашаса, баласының тәне шул хәрамнан туплана. Хәрамнан җыелган гәүдә исә киләчәктә хәрам нәрсәләрне эзләп, хәрам гамәлләр кылудан тәм табачак, ә әти-әнисе: “Нигә бу бала мондый булды икән, без бит аны начарлыкка өйрәтмәдек...”, – дип аптырап кайгырачак, үзләренчә бала хакына дип дога да кылачак, әмма бу дога кабул ителерме һәм баланы шайтан җәтмәсеннән коткарып булырмы? Иншә Аллаһ, ләкин моның өчен бик тә, бик тә ихласлы, елый-елый дога кылырга кирәк; әмма ...
- нинди дә булса хаталарың, гөнаһ-кимчелекләрең булуны беләсең икән, дога кылганчы тәүбә итәргә, Аллаһтан гафу үтенергә кирәк (кемнедер рәнҗеткән-үпкәләткән булсаң – шул кешедән кичерүне сорарга);
- Аллаһы Тәгаләдән нәрсәдер сорар алдыннан нинди дә булса яхшы, саваплы гамәл эшләргә киңәш ителә (сәдака бирергә, мохтаҗ кешегә ярдәм итәргә һәм башкалар);
- галимнәр дога кылыр алдыннан тәһарәт алып 2 рәкәгать хаҗәт намазы укырга киңәш итә;
- дога кылыр алдыннан шәхсән үзең өчен нәрсәдер сораганчы Аллаһны мактарга, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә салават-шәриф әйтергә кирәк. Аннан соң барлык пәйгамбәрләр, сәхабәләр, галим-остазларыбыз, вафат булган туганнарыбыз өчен дә хәер-дога кылып, ахырда гына үз хаҗәтләреңне Аллаһка белдерү хәерле була;
- сораган нәрсәне бер генә тапкыр түгел – кат-кат сорарга: башка гыйбадәтләр кебек, доганың да дәвамлы булуы мөһим ;
- Аллаһка мөрәҗәгать итеп нәрсәдер сораганда тулы инану белән, ихлас тәвәккәлләп, догабызга һичшиксез җавап бирелер диген ныклы ышаныч белән дога кылырга кирәк;
- дога кылуның күркәм әдәпләрен – дога кылганда ике кулны учлары белән өскә таба юнәлтеп күтәрү, дога кылып бетергәч ике уч белән битне сыпыру һәм ахырда тагын бер кат Аллаһны мактап шөкер сүзләре әйтүне истә тоту да әһәмияткә ия.

Аллаһ Раббыбыз Белүче, Күрүче, Ишетүче. Ул Юмарт, Мәрхәмәтле, Гафу итүче. Аллаһ сүбхәәәнәһү вә Тәгалә кылган гөнаһларыбызны ярлыкасын, безне туры юлга күндерсен, гыйбадәтләребезне кабул итсен. Дога олы гыйбадәтләрнең берсе булуын онытмасак иде. Ә кылган догаларыбыз тормышка ашмаса, монда ниндидер хикмәт барлыгын аңлап, өметебезне өзмик, көтик, сабыр итик, Раббыбызны танып Аңа мөрәҗәгать итә алуыбызга сөеник, ихлас күңелле мөэмин-мөселманнар булып яшик.

**Ришат КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

## КОРБАН ЧАЛГАНЧЫ АЯГҮРӘ БАСЫП УКЫЛА ТОРГАН ДОГА


**Бу дога Коръәни Кәримдә китерелгән һәм аны корбан чалганчы укырга кирәк: “Иннии үәҗҗәһтү үәҗһийә лилләзии фәтарас сәмәәүәәти үәл әрда хәниифәү үә мәәә әнә минәл мүшрикиин” (Батылдан хакка авышканым хәлдә җир һәм күкләрне төзүче Аллаһыга йөземне юнәлдердем һәм мин Аллаһыга һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылучы түгелмен) (“Әнгам” сүрәсе, 79 нчы аять).**

## КОРБАН ЧАЛГАННАН СОҢ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

**Корбан чалганнан соң ике рәкәгать намаз уку сөннәт була. Намаздан соң шушы доганы укырга кирәк: “Иннә саләәтии үә нүсүкии мәхьйәәйә үә мәмәәтии лилләәһи раббил гәәләмиин” (Укыган намазларым һәм бугазлаган корбаннарым фәкать Аллаһы ризалыгы өчен генә эшләнә һәм тере булуым да, үлүем дә бөтен галәмнәрне тәрбия кылучы Аллаһы Тәгалә эше) (“Әнгам” сүрәсе, 162 нче аять).**

## КОРБАН ЧАЛУЧЫ КЕШЕ ДОГАСЫ

**Корбан чалучы кеше корбан хайванын бугазлаганчы тәкбир әйтергә тиеш: “Аллааһу әкбәр. Аллааһу әкбәр. Ләәә иләәһә илләллаһу үаллааһу әкбәр. Аллааһу әкбәр үә лилләәһил хәмдү” (Аллаһы бөек. Аллаһы бөек. Аллаһыдан башка иләһ юк, һәм Аллаһы бөек. Аллаһы бөек һәм барча мактаулар Аллаһы Тәгаләгә генә).**



# Кояшта җылынган су белән тәһарәт алырга ярыймы?



Гомум кабул ителгән фикъһ чыганаклары буенча кояшта калдырылган бакыр, җиз һәм алюмин савытлардан тәһарәт алу - мәкруһ. Бу хөкем "...кояшта җылытылган су махау авыруына (проказа) сәбәп булып тора", - дип әйтелгән хәдискә нигезләнә (Зәйлаги, Тебйинел-Хакаик, I, 87; Ибнел-Хөмәм, Фәтхел-Кадыйр, I, 56; Мәверди, әл-Хәвил-Кәбир, I, 52). Ләкин бу – зәгыйфь хәдис (Бәйхаки, әс-Сөнәнел-Кубра, Тәһарә, 7; Даркутни, әс-Сөнән, Тәһарә, 7; бине Кудама, әл-Мугни, I, 46).

Яңа чыганаклардан күренгәнчә, балчыктан эшләнгән кувшин, комган, чүлмәк кебек савытлардан тәһарәт алуда бернинди дә начарлык юк (Ширбини, Мугнил-Мохтаҗ I, 19; Хәшийәтел-Бөҗейремиәләл-Хатиб, I, 244). Чөнки мондый савытлардагы су нинди дә булса авыруга сәбәп була алмый. Хәзерге көндә кояш энергиясе аша җылынган суны куллануда зарар юк. Шуңа күрә дини күзлектән караганда андый су белән тәһарәт алуда яки госел коенуда начарлык юк.

# Өйдә мәче тотарга ярыймы?

Өйдә (йортта) мәче тоту тыелмый. Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Мәче – пычрак хайван түгел. Ул һәрвакыт безнең тирәдә бөтерелә торган хайван!" (Әбү Давыд, Тәһарә, 38: Тирмизи, Тәһарә, 69). Әнәс ибне Мәликтән бу хакта сорагач, ул түбәндәгечә җавап биргән: "Бервакыт без Аллаһының Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән Бухтани дип аталган урынга баргач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәһарәт алу өчен су әзерләргә кушты. Аллаһының Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәһарәт алу өчен әзерләнгән савыт янына килгәч, мәченең шул савыттан су эчеп торганын күреп (мәченең су эчеп туктаганын) көтә башлады. Мин аннан: "Суны алыштырыргамы?" - дип сорагач, ул: "Ий Әнәс, мәчеләр бернәрсәне дә пычратмыйлар, алар – чиста хайван," – дип җавап бирде (Әт-Тәбәрани әл-Мөҗәм әс-Сәгыйр 1/379, әл-



Хәйсәми "Мәҗмә Әз-Зәваид" 1/216).


Кайбер галимнәр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: "Мәче – ерткыч хайван", - дигән сүзләренә нигезләнеп, мәченең селәгәе чиста түгел дип исәпләүләр. Ләкин мәчеләрнең селәгәе чиста дигән фикер күпкә дөресрәк. Шуңа да карамастан, кешенең мәчегә кулын яларга биреп, аннары аны юмыйча намазга басуы – мәкруһ (хупланылмаган, монда мәкруһ-тәнзих күз алдында тотыла) гамәл. Шулай ук, кешенең ашарына башка ризыгы була торып, мәчедән калганны ашау хупланылмый. Әмма кеше ярлы булып, аның башка ризыгы юк икән, бу (мәчедән калганны ашау) кире кагылмый ("Мәрәкел-Фәләх", "Шәрех Нур әл-Идах" китапларыннан).

Шәфигыйлар имамы Нәвави йорт мәчеләрен сатуалу турында сөйләгән вакытта үз мәзһәбе фикерләре белән бергә Әбү Хәнифә имамның карашларын да җиткерә: "Безнең мәзһәбтә йорт мәчеләрен сатып алуның [һәм сатуның] рөхсәт ителгәнлеге турында фикер каршылыклары юк. Күпчелек галимнәр дә бу фикерне яклый (Хәнәфи мәзһәбе сатуны хупламаса да): ибне Габбас, Мәлик, әс-Саури, Әхмәд... Тыю турындагы хәдискә килгәндә исә, нигезле ике җавап бар. Беренчесе: монда кыргый мәчеләр күз алдында тотыла, икенчесе: анда тыелу турында сүз бармый, ә хупланмаган гамәл булуы әйтелә." [Имам ән-Нәвави] Шарех әл-Мөхәззәб.

# Хатын-кыз хиҗап (яулык) киеп йөрмәсә, аның намазы кабул буламы?

Намазның кабуллыгының бер кагыйдәсе булып хатынкызның бар гәүдәсенең (бары йөз, беләзеккә кадәр куллар һәм аяк йөзенең ачык булуыннан кала), шул исәптән чәчләрнең дә каплаулы булуы тора (Хәнәфи мәзһәбе буенча). Әгәр хатын-кыз намаз вакытында чәчен капламаса, аның намазы кабул булмый.

Гадәти вакытта яулык кимәгән хатын-кыз, намаз укыганда гаурәтен капласа, аның намазы иншә Аллаһ кабул булачак. Аның намаздан калган вакытта яулык бәйләмәве, намазының дөрес булу-булмавына кагылмый. Ә киресенчә, көндәлек намаз уку барыбер аны кайчан да булса яулык бәйләүгә китерәчәк. Коръәни Кәримдә әйтелгәнчә, намаз ул - кешене яхшылыкка дәртләндерә һәм яманлыктан саклый торган гыйбадәт. Мөслимәгә яулык бәйләү һәм намаз уку фарыз, шуңа да ул әлеге бурычларны тиз арада үти башларга тырышырга тиеш. Әгәр аның туганнары намаз укуына каршы икән, ул әлеге гыйбадәтне аларга белгертмичә дә башкара ала.



Яулыкка килгәндә исә, өйдә чәчләрне каплап йөрү мәҗбүри түгел, ә менә урамга чыкканда бу мәҗбүри. Шулай ук яңа гына дингә кереп килүче, барлык бурычларны да берьюлы үти башлый алмаганлыктан, әкренләп шәригать законнарын өйрәнергә һәм аларны башкарырга омтылырга тиеш. Аллаһы Раббыбыз – төп хөкем чыгаручы, Ул һәркемне хәленә карап хөкем итәчәк. Раббыбыз беркайчан да Үзенең колына карата гаделсезлек күрсәтми.

Аллаһы Тәгаләгә күбрәк мәгълүмдер.

# Коръәнне яткан килеш укырга ярыймы?

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: "Дөреслектә җир вә күкләрнең төзелешендә, төн белән көннең бер-берсенә хилаф булышында гакыл ияләренә Аллаһының барлыгына һәм берлегенә ышанырга, әлбәттә, көчле дәлилләр бар. Ул гакыл ияләре, намаз укырлар, намаздан башка вакытта да Аллаһыны зикер итәрләр: баскан, утырган вә яннарына яткан хәлдә, дәхи җир, күкләрнең төзелеше хакында гакылларын эшләтеп, фикерләрләр: "Ий Раббыбыз, бу төзелешне Син максатсыз бушка гына төземәдең. Мактау Сиңа, Син барча кимчелектән пакьсең! Безләрне ут газабыннан сакла!" ("Әлү Гыймран" сүрәсе, 190-191 нче аятьләр). Бу аятьтә Аллаһының аягүрә, утырган һәм яткан килеш, ягъни һәрвакытта искә алырга киңәш ителә. Моңардан күренгәнчә, Коръән ул – зикер, ягъни Аллаһы Тәгаләне искә алу, шуңа да Коръәнне яткан килеш тыңлау яки укуда бернинди дә гаеп юк. Ләкин Коръәнне тыңлаучыда да, укучыда да аңа карата хөрмәт хисе булырга тиеш.

Коръәни Кәримне кыйблага каршы карап утырып, зур ихтирам хисе белән уку киңәш ителә.



Җаваплар tat.islam-today.ru сайтыннан алынды

# Аллаһыга якынаю юлына чакырам

**Сентябрь аеның 24 нче көнендә иртәнге сәгать 6 да, Аллаһы насыйп итсә, Корбан гаетенә ирешербез. Бу бәйрәм һәрбер мөселман кеше өчен ел дәверендә иң олуг булган көннәрнең берсе. Халкыбыз, әлхәмдулиллаһ, шушы бәйрәмгә мәчетмәхәлләләребезгә килә, намазларында катнаша, корбан чалу вә махсус ашларын уздыру йолаларын үти. Бу бик шатлыклы һәм сөенечле хәл! Әгәр шушы изге гамәлләр барысы да Аллаһы ризалыгын өмет итеп башкарылса, һичшиксез, алар әүвәл үтәүче кешенең үзенә, аннары авылларыбызга, районнарыбызга вә җөмһүриятебезгә бәрәкәт нурлары булып кайтыр.**

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Белгәнебезчә бүген белем, информация заманасы. Хәзер кешене сөйләп кенә һич ышандырып булмый, ул нәрсәдер ишетсә, шул мизгелдә үк аны тикшерергә ашыга. Шуңа күрә бүген кешенең корбан йоласын үтәү генә түгел, аның мәгънәсенә вә хикмәтләренә төшенәсе килә.

Аллаһы Тәгалә безне бу тормышка ял итәргә яки аны уенда уздырырга җибәрмәде. Без кешеләр гомеребезнең һәр мизгелендә бу дөнья белән зур көрәштә. Кагыйдә буларак, табигый сайланыш бара, һәр җан иясе үзен саклар өчен көрәш сынавы уза. Кайда һәм нинди вакытта яшәсәк тә, без Аллаһы тарафыннан язылган гомеребез буена имтихан тотабыз. Коръәндә моның хакында болай әйтелә: "Сезне авырлык вә шатлыклы хәлләр белән бу тормышыгызда сынарбыз. Шуңа да онытмагыз, сезнең кайтуыгыз безнең янгадыр" ("Пәйгамбәрләр" сүрәсе, 35 нче аять).

Иң авыр сынауларны узган кешеләр - Аллаһының илчеләре, пәйгамбәрләр. Алар өстенә төшкән бәлаләрне, үзләре вә гаиләләре күргән авырлыкларны сөйләп бетерерлек түгел. Кыскасы, бу изге кешеләр безнең өчен сабырлык төшенчәсен дөрес итеп аңлауда иң зур мисал булып торалар.

Ибраһим галәйһиссәламне дә Аллаһ бик зур авырлык белән сынады. Ул аңа үзенең улы Исмәгыйльне чалырга әмер бирде. Ибраһим галәйһиссәлам шушы кушылган эш турында күп уйлады, бераз шикләнеп тә куйды. Ләкин Раббысы аны кабат шушы корбанны чалуга этәрде. Көннәрдән бер көнне, малае белән ул тауга менде. Улын ташка яткызып, үткен пычагын чыгарды. Шикләнеп, "дөрес эшлим микән?!" дип, ул улына карады, тегесе бер дә курыкмыйча: "Йә әткәм! Аллаһ сиңа нәрсә боерды – шуны үтә. Кайгырма, Аллаһ теләсә, син мине сабыр итүчеләрдән табарсың", – дип, атасын үгетләде. Шушы сүзләрдән соң Ибраһим галәйһиссәламнең күңелендә шик калмады, ул пычагын күтәреп: "Раббым Аллаһы кушканны үтимен, бисмиллаһ", – дип ният кылуы булды, шул мизгелдә аның кулын фәрештә тотты, Аллаһыдан вәхий иңде: "Йә Ибраһим! Хаклыкта, син төшеңдә кушылган әмерне үтәдең. Менә ошбу рәвештә Без изгелек кылучыларны бүләклибез. Менә шушында сиңа Аллаһның ачыктан-ачык сынавы иде". ("Саффәт" сүрәсе, 104-106 нчы аятьләр).

Раббыбыз Аллаһы явыз зат түгел, Аның хөрмәтенә кешене чалуда ихтыяҗ юк. Әмма Аллаһының максаты – кешегә авыр эшне боерып, шуның үтәлүе рәвешен карау. Һичшиксез, Аллаһы Тәгалә Ул болай да бар нәрсәне күрә һәм белә. Ләкин без, адәм балалары, Кыямәттән соң җәһәннәм чокыры яисә оҗмах капкалары кырыенда басып торганда "нигә мин анда керәм?" дигән сорау тумасын өчен шушы тормышыбызны яшибез. Бу гомер үзе бер имтихан, аны ничек бирәбез – үзебезгә шундый ахирәт алабыз.

Күбегезгә мәгълүм, корбан гарәп теленнән "сарык" яки "чалу" дип тәрҗемә ителми. Бу сүзнең турыдан-туры мәгънәсе ул "Аллаһыга якынаюдыр". Ә Аллаһыга ничек якынаеп була? Раббыбыз тарафына якынаю ике төрле була. Берсе - физик рәвештә көн саен яшәп Аллаһы белән очрашуга якынаю. Моннан качып та, вакытны тизләтеп яки соңартып та булмый. Бу сиңа ничек язылган, шулай була. Якынаюның икенче төре - изге гамәлең белән Аллаһыга исән чагыңда якынаю. Әле көч-хәлең, зиһенең бар, башың эшли – булдыра алган кадәр Аллаһыны олугла. Тәнең гыйбадәттә, телең зикердә, йөрәгең Коръән турында фикерләүдә булсын. Менә шушы изгелек Аллаһыга якынаю юлы дип атала. Бу юл өч көнлек яки бер айлык кыска гына сукмак түгел, ул безнең тормышыбызның башыннан ахыргы сулышыбызга кадәр булган сәфәр.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, шушы изге Корбан гаетендә сезне Аллаһыга якынаю дип аталган юлга беренче адымны ясарга чакырам. Йолаларыбызны үтәп, корбаннарын чалып, намазларын укып, тәсбих-догаларын кылып, тормышыбызның һәр мизгелен Аллаһыга якынаюда уздырсак иде!

**Хәбир хәзрәт ХАНОВ,
Чирмешән мәчете
имам-хатыйбы**

# Яңгыр түгел, боз яуса да җыелучыларбыз!

**Мөслимә ШӘФЫЙК**

**Иртә таңнан кояш киң елмаеп сөендерсә дә, бик тиз арада бөтен күк йөзен болытлар каплады. Менә без Гөлзадә остазбикәбез белән очрашып, куанышып Шәкертләр мәйданына атлыйбыз. Бүген безгә Мәрҗани мәчете чатырын биргәннәр, Әлмира остаз шуннан кул болгап чакыра. Мансур хәзрәт Җәләлетдингә Алаһының рәхмәтен укыйукый, халык әкренләп җыела башлады. Ярдәм мәчетендә коръәнхафизлыкка укып йөрүче шәкертләр дә килеп җитте. Тышта яңгыр коя гына. Кардәшләребезнең йөгерешеп кергән берсе белән кочаклашып күрешәбез, Җөмһүриятебезнең бәйсезлеге көне – бәйрәм белән котлашабыз. "И-и, бу бит безнең иң көтеп алган олы бәйрәмебез, - ди профессор Лена Кәлимулла кызы Таҗиева, битендәге яңгыр тамчыларын сөртә-сөртә. – Ничек килмисең! Без инде яңгыр түгел, боз яуса да җыелабыз.**



Иң яшь шәкертебез Инсаф Коръән сүрәләре белән мәҗлесне ачып җибәрде. Атаклы Сәйдә Аппакова матур итеп дога кылды. Дәүләт милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре хаҗия Флера Дәминова беренче булып сүз сорады, чөнки музейда үткәрәсе чараларга әзерлек эшләрен башкарасы бар икән. Бәйрәм белән котлаганнан соң, ул барыбызны да тарихыбыз, мәдәниятебезгә багышланган шул чараларга чакырды.

– 25 ел үтеп тә киткән, кардәшләрем! Ә бит барысы да бүгенгедәй хәтердә, - дип башлады сүзен шушы очрашуны 15 нче мәртәбә оештыручы остазбикәбез Әлмира Әдиатуллина. - Ирек мәйданы Идел дулкыннары кебек иде ул чакта. Халык көн-төн мәйданда булды. Җөмһүриятнең балкышы иде бу! Суверенитет игълан ителгән төндә Ирек мәйданын тутырып, өч рәткә түгәрәкләшеп тезелеп биедек. Бер ягымда - Мөслимә ахирәтем, икенче ягымда - Вафирә газизебез! Аяклар җирне тоймый, очарга әзер идек бит!

– Бик күп авырлыкларны җиңеп, безне шушы көнгә җиткергәнегез өчен, милләтне дингә кайтаруыгыз, намазга бастыруыгыз өчен рәхмәт сезгә, – диде Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе Тәбрис Яруллин. - 25 ел – Татарстаныбызның данлы сәхифәсе. Күңелләребез горурлык хисләре белән тулы. Сез ялуган суверенлык байрагы ышанычлы кулларда! Безнең бүгенге чараларыбыз – сез аксакалларга, остазбикәләргә җавабыбыз ул.

Әдәп-әхлак бәйгеләре җиңүчесе сигез яшьлек Билал бәйрәмгә әти-әнисе белән килгән. Ул, гадәттәгечә, "Фатиха", "Аятел-көрси" һәм башка изге сүрәләрне гүзәл мәкам белән укып сөендерде. Аллаһының рәхмәте киң, шөкер, дәвамчыларыбыз бездән дә уздыра.

Нагорный бистәсеннән мәҗлесебезгә беренчеләрдән булып килгән Иман нуры мәчете мәдрәсәсе мөгаллимәсе Гөлзадә Шәяхмәтованы тыңлап туймассың!

– Алаһының ризалыгы өчен изге эшләр эшләвем белән бәхетлемен. Йортларыбызга, ил-көннәребезгә иминлек, балаларыбызга тәүфикъ-һидаят, дуслык, хәләл кәсеп, хәләл ризык сорыйм. Кодрәтең зур, рәхмәтең киң, йә Раббым! Гөнаһларыбызны гафу кыл, гомеребезнең ахырын хәерле кыл. Иман кәлимәсе күңелебездән китмәсен...

Сөбханаллаһ! Кардәшләребезнең берсеннән-берсе могтәбәр булуы нинди зур сөенеч! Менә безне куандырган Билалның әтисе Хәйдәр Нурислам улы Камалетдинов сүз алды. Хәзрәтебез Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге җитәкчесе һәм әле тагы да гаҗәпләндергәне – иман юлына аяк баскан чакларыбызда вәгазьләре белән гыйлеме белән сокландырган остазбикәбез мәрхүмә Рауза апаның оныгы икән!

– Республикабызда 1530 мәчет бар хәзер. Иман юлларыбыз ачылды, шөкер. Шушылай бергә җыелышулар бик кирәк. Авырлыкларга карамастан, милләтебез, динебез өчен күп эшләр башкаручы Әлмира апага рәхмәт. Исламга хезмәт итү – иң зур дәрәҗә. Аллаһы Тәгалә юлында булу – олы бәхет.

**(Ахыры 15 нче биттә.)**

# Бәйрәм вә сабыйлык вакыты

*Габдулла ТУКАЙ*

Сабый вактын сагынмакта һәр шагыйрь дә,
Ачы-тәмле хыялдыр бу һәр шагыйрьгә;
Бәйрәм җитсә, минем дә исемә төшә:
Уйнамакчы булам сыйбьян* берлән бергә.

Төшә искә Гарәфә кич яткан чагым,
Уйлап: «Кайчан таң?» - дип, ул атмаган таңым;
Тәти читек, тәти күлмәк-ыштаннарны
Баш астыма өеп куеп яткан чагым;

Таң алдыннан яңлыш йоклап киткән чагым,
Төшемдә дә нурлы бәйрәм көткән чагым;
Әнкәемнең тавышлары колагымда:
«Гает җитте, тор, аппагым! тор, аппагым!»

Таң аткачдин урам буе чапкан чагым,
Мәгъсуманә** ләззәт, хозур тапкан чагым;
Корбан ите, төрле тәмле аш өстенә,
Гает укып, көлә-көлә кайткан чагым.

Уйласаң ул якты көнне, килә күз яшь,
Хозур ла соң! инсан өчен бу хәл, бу яшь!
Бәйрәм көнне күктән җиргә нурлар ага,
Әйтерсең лә чыккан бу көн ике кояш!

Төңре! чигерче яшемне, синнән сорыйм;
Теләгемне синнән сормый, кемнән сорыйм;
Бәйрәм көнне генә сабый булып торыйм,
Рәхәтләнеп, сикреп, көлеп, уйнап йөрим!

---------

***Сыйбьян – балалар.***
****Мәгъсуманә – гөнаһсыз, пакь килеш.***



Ирик МУСИН

# Мөселманчылыкмы бу?

**Ислам дине килгән заманда гарәпләрдә гыйлеме Аллаһка гына хас булган гайбтән (гайб - ул Аллаһы Тәгалә генә белә торган, бездән яшерен булган белем, киләчәк; безнең ул белемне белергә мөмкинчелегебез юк) хәбәр бирү (ягъни күрәзәчелек белән шөгыльләнү), сәфәргә чыкканда кайбер кошларның очравыннан шомланып, чыкмый калу, үзләре яхшы дип белгән нәрсә очраса, "әлбәттә, бу юлым хәерле булачак" дип ышану шикелле бозык ышанулар, игътикадлар тәмам таралган иде.**

Ислам дине килү белән, бу батыл, ялган ышануларны җимерде: "Гайбне Аллаһтан башка һич кеше белмәс. Исламда шомлану юк", - дип безгә ачык әйтте. Гайбтән хәбәр бирү хәтта Аллаһның яраткан Пәйгамбәре Мөхәммәдкә дә бирелмәде. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә шундый аять тә иңдерде: "Әйт: "Мин гайбне белмим, әгәр белсә идем киләчәк көнләр өчен күп яхшылык әзерләп куяр идем".

Инде Аллаһы Тәгаләнең якыннары, дуслары булган пәйгамбәрләрдән дә яшерелгән бу белемнең башкаларга бирелмәве башында аз гына акылы булган кешегә дә ачык. Без дә шушы ислам дине бәхетенә ирешкәнбез, бозык ышанулардан пакь булган дин белән Аллаһ безне бәхетле иткән, ләкин, кызганычка каршы, халкыбызда булган хәлләрне тикшерсәк, исламияттән тәмам ерактабыз. Әбүл-Галә әл-Мәгарри хәзрәтләренең: "Әгәр кешеләрнең ышануларын сорашсаң, йөзләрне кызартырлык нәрсәләр ишетәсең", - дигән мәгънәдә булган бер шигыре бар. Хакыйкатьтә безнең мөселманнар арасында игътикад-ышанулар турысында сөйләшә башласаң, йөзне кызарту түгел, оялуыңнан җир астына керерлек сүзләр ишетәсең һәм шундый вакыйгалар күрәсең.

Үз илемездә (Минзәлә өязе) югарыда искә алынган мәсьәләләр җөмләсеннән "шомлану"ны күрергә байтаграк туры килә торган иде: ала карга очрап юлдан кире кайтучыларны күп ишетә идем. Иң элек көтү чыкканда алдан кызыл сыер чыкса, әлбәттә, янгын була, яшь киленне алып кайтканда атка яки арбага берәр зарар килсә, ир белән хатын арасында әлфәт мәхәббәт булмый, аерылышалар яки гомер буе талашып яшиләр, дигән сүзләрне олы картлардан, абыстайлардан ишетә идем. Табигый, мин боларга гаҗәпләнеп каршы төшә идем, ләкин "без моны гомеребездә берничә мәртәбә сынап карадык инде" дип кирелекләреннән һич кайтмыйлар иде.

Менә әле дөньяда яши торгач, боларыннан да хәтәр булган ышануларны ишетергә туры килде. Дөньяның агымы бу елны мине Вятка губернасы Иж заводына китерде; монда ике мәхәлләдән гыйбарәт мөселманнар җәмәгате бар. Шул мөселманнарның тормышлары, ышану-инанулары белән шактый таныштым һәм боларны ышану турысында тагы да начаррак хәлдә таптым. Мине бу юлларны язарга мәҗбүр иткән вакыйга да үз күз алдымда булып үтте.

Шулай торган фатирыбызда бер егетнең ун сумнан артыграк акчасы югалды. Менә шушы акчаны кем алганын белү мәсьәләсе кузгалды. Югалтучы үзебезнең катыбызда торган бер чал сакаллы кешедән шикләнә иде. Карт нинди кешедер - анысы мина мәгълүм түгел, ләкин шул вакыйганы ишеткәч: "Мин инде карт кеше, андый вакытларым үткән", - дип елады. Халык күп кенә - төрле губерна, төрле өяздән җыелган. Хатыннар, яшүсмер егетләр бар. Бер вакытны араларында шуны кем алганын хәл кылу турысында киңәш булды һәм бер авылдан күрәзә (көзгедән багучы) хатынга барырга карар бирелде. Аның кем алганын белүендә берсе дә шик кылмый иде. Мин вакыйганы тыңлаптыңлап утырдым да: "Соң безнең Русия нинди киң, һәр вакытта диярлек, зур суммалар югалып тора. Хөкүмәт тә боларны тикшерү өчен никадәр зур чыгымнар тотып яшерен политсәләр куя. Алар ник сезнең күрәзәчеләргә генә килмиләр икән", - дидем. "Аны хөкүмәтнең беләсе бар әле", - диделәр. Арадан күпне күргәнрәк бер хатын торып: "Бер елны безнең хәситәбез югалган иде. Шул хатынга барып көзгедән караттык. Фәлән хатынның качып, яшеренеп, як-ягына каранып сандыктан алуына кадәре күрсәтте", - дип миңа сөйләп маташырга да урын калдырмады.

Карар булды. Күрәзәче хатынга барудан элек карта ачучы хатынга (үз йортыбызда торучы хатын) карта ачтырдылар. Хатын: "Бер чал сакаллы кара кеше алган", - дигән. Шиксез, карт үзе дә болар белән бер ышануда, хатынның шул сүзен ишеткәч: "Ант итәм алмадым, ләкин ул билге миңа туры килә. Шулай булгач, алмасам да үз акчамны бирәм", - дип чыгарып бирде, һәм дөресрәк булсын өчен хатынга бардылар. Ул да картачы хатынның сүзен әйткән, имеш. Эш тәмам булгач, миңа: "Күрдеңме менә!" - диделәр.

Уйлагыз, кардәшләр! Мөселманчылыкмы бу? Безгә оят түгелме? Әле бу җөмләдән берсе генә, мондый бозык инанулар арабызда бик күбәйгән. Үзләре шушы ышануларда булып та телләрендә "дин" генә, әгадәтләренә каршы бер сүз әйтсәң, сиңа динсезлек мөһере әзер тора. Я, Раббым, мөселман колларыңны туры юлга күндер.

**Зәки УРАЗАЙИ,**
**"Мөхәммәдия" укытучысы**
**"Дин вә әдәб", 1916 ел, 3 сан**
**Язманы Фатих ХӘБИБ**
**әзерләде**

# Яңгыр түгел, боз яуса да җыелучыларбыз!

**(Ахыры. Башы 14 нче биттә.)**

Аның нигъмәтләрен кешеләр арасында тарату – мөселманның иң төп бурычларыннан берсе, дигән Пәйгамбәребез Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм). Аллаһы кушканнарны тарату, вәгазь сөйләү, үз тормышың белән үрнәк күрсәтү – менә нинди булырга тиеш мөселман. Алдынгы үрнәк, гаделлек үрнәге күрсәтүчеләр булырга... Җыелуларыбыз мөбарәк, бердәмлегебез дәвамлы булса иде.

- Бу көрешү, фикерләшү бәйрәмебез дәвамлы булсын, - дип башлады сүзен тарихчы галимә, язучы Тәэминә Биктимерова да. – Халкыбыз гомергомергә гыйлемгә омтылган, гыйлемле, мәгърифәтле булган. Татар хатынкызларының ислам дине, мәгърифәт юлындагы тиңсез батырлыклары турында күпме генә язылса да аз, әле безнең ачылмаган тарих битләребез биниһая күп. Татарның гүзәл кызлары – Фатыйма Аитова, Хәдичә Ямашева исемнәрен олылау зарур. Аитова атасыннан калган мирас белән 1908 елда кызлар өчен һөнәр мәктәбе, 1916 елда татар кызлары гимназиясен ача. Хәзер 12 нче кызлар гимназиясе аның исемен йөртә. Хәдичә Ямашева (Хөсәен Ямашев хатыны) 1917 елда Бөтенроссия татар хатын-кызлары съездын оештыра. 1937 елда кулга алына, Ухта төрмәсендә 10 ел утыра... Газизләребезнең авыр туфраклары җиңел булсын.

Бик матур милли киемнәрдән йөрүче Мансура Гыйльметдинова-Солтанова бәйрәмебезгә "Еллар агышында – кеше язмышы" дигән китабын алып килде. Гаҗәеп авырлыклар, авыр сынаулар үткән икән ул кардәшебез дә! Балачакта сугыш елларындагы ачлыкны, кырсытуларны кичергән. Бу юлы ул өр-яңа мөнәҗәт башкарып күзләрдән яшьләр чыгарды. "Мәчет манарасын кискәч, бабамның көн дә шунда барып "Йәсин" чыкканын, шулхәтле елап йөргәннәрен хәтерлим", – дип тәкъдим итте ул мәчет манарасына багышланган мөнәҗәтен.

Сәйдә Аппакова - бүгенге көндә гаилә бәхете, милләтебезне саклауда гаиләнең, ир белән хатынның бурычлары мәсьәләсендә олы белгечкә әйләнеп киткән абыстаебыз."Иң мөһиме – иман, иң мөһиме – никах, бәхет ачкычы – әнә шунда, - диде ул. – Иманда нык булыйк, кызларыбыз-уллырыбызның никах белән гаилә корулрына ирешик".

Мөхтәрәм профессорыбыз Лена Таҗиева сөйли:

- Җөмһүриятебезнең 25 еллыгы гаҗәеп тантана, дусларым! Миңа Казан, Санкт-Петербург, Каһирә университетларында уку насыйп булды. Мисырда Татарстанны белмиләр иде, анкета тутырганда Россия дип язып куйдылар. Ә бүген татарны, Татарстанны, Казанны бөтен дөнья белә! Бу бәйрәмдә безнең дә өлешебез бар, шөкер!

Хәмид Вәлиди үзенең яңа шигырьләрен укыды, милләтенә иман байлыгы, бәхет теләде.

Зөһрә-йолдызыбыз Сәхабиева да бәйрәмгә кайтып җитеште. Чувашстанның Тукай авылында мәдрәсә ачылу тантанасында булган икән.

- Ий, җәмәгать, андагы кардәшләребезнең матурлыгы... Алар белән күрешү шатлыгын сөйләп бетерергә сүзләр җитмәс. Яулыкларын нәкъ безнең әниләрчә бәйләгәннәр. Андагы муллык, гүзәллек, динилек... Сокланып, сөенеп туялмадым. Татар кайда да үз кыйммәтен белә, шөкер.

Зөһрәнең "Уракчы кыз"ы, "Җидегән чишмә"се безнең күңелләрне дә халкыбыз өчен, Татарстаныбыз өчен чиксез горурлык хисләре белән тутырды

# РИИ мөселман журналисты мәктәбенә чакыра

***Россия ислам институты мөселман журналисты мәктәбенә тыңлаучылар җыя башлады. Аның кысаларында мәктәп укучыларын киләчәктә РИИның “Журналистика” юнәлешенә укырга керү өчен рус теле, әдәбияты, җәмгыять белеменнән БДИ тапшыруга әзерләү күздә тотыла. Дәресләр бушлай үткәрелә, дип хәбәр итә уку йортының матбугат хезмәте.***

Мөселман журналисты мәктәбе октябрьдән эшли башлый. Дәресләр киләсе елның маенда тәгәлләнәчәк. Укучыларны БДИга РИИ доцентлары әзерләячәк. Шулай ук мәктәп кысаларында журналистика нигезләре буенча да белем бирү планлаштырыла. Бу дәресләр журналист белгечлеге белән якыннанрак танышырга һәм иҗади имтиханга әзерләнергә ярдәм итәчәк. Укучыларны интернет-газета редакциясе булдыру, фотоюнәлеш буенча кызыклы мастер-класслар көтә. Дәресләр атнасына 2 тапкыр кичке якта уздырыла.

# Әдәби гарәп теле курсларына рәхим итегез!

***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Казан федераль университеты дин әһелләре (имамнар, мәчеттә эшләүчеләр, дини уку йортлары мөгаллимнәре) өчен әдәби гарәп теле буенча курс уздыра.***

Уку вакыты: 2015 елның апрель-декабрь айлары, 2016 елның февраль – декабрь айлары. Дәресләрне гарәп теле белгечләре уздыра. Укулар тәмамлангач, КФУ таныклыгы бирелә. Курс түләүсез.

Тулырак мәгълүматны Россия ислам институтында (Казан, Газ урамы,19. 318 кабинет) 29 сентябрьдә 18 сәгать 30 минутта үткәреләчәк оештыру җыелышында белергә мөмкин.

ХӨРМӘТЛЕ ДИН КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ!

Сезне олуг бәйрәмебез Корбан гаете белән тәбрик итәбез.
Корбан бәйрәме ислам традицияләренең, кешенең милләтенә һәм диненә карамыйча, гаделлек, яхшылык, рәхим-шәфкатьлелелек, кайгыртучанлык кебек мәңгелек кыйммәтләргә нигезләнүен тагын бер кат исебезгә төшерә. Корбан бәйрәме – яхшы гамәлләр кылу, мохтаҗларга ярдәм итү һәм дус-туганнар белән аралашу ул.
Бу – гасырлардан гасырларга сакланып килгән традиция.
Бу көнне туганнарыгыз, дусларыгыз белән каршы алуыгызны телибез.
Зур бәйрәм өстәлегезне бизәү өчен «Хәләл» стандартларына туры килүче ризыкларны сез һәрвакыт «Бәхетле-Хәләл» кибетендә таба алаcыз.
Адресыбыз: Казан шәһәре, Г. Тукай урамы, 64.

*Тәннәрегезгә – сәламәтлек, күңелегезгә – шатлык, рухи һәм материаль байлык, тынычлык һәм иминлек телибез сезгә!*

Бәхетле
СУПЕРМАРКЕТ ДОМАШНЕЙ ЕДЫ
ХАЛЯЛЬ

# КАЗАН ӨЧЕН ОКТЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Таң беленә | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.10.2015 | 03:40 | 04:15 | 05:45 | 12:00 | 15:19 | 17:20 | 19:01 |
| 02.10.2015 | 03:42 | 04:17 | 05:47 | 12:00 | 15:17 | 17:17 | 18:59 |
| 03.10.2015 | 03:44 | 04:19 | 05:49 | 12:00 | 15:15 | 17:15 | 18:56 |
| 04.10.2015 | 03:46 | 04:20 | 05:50 | 12:00 | 15:13 | 17:12 | 18:53 |
| 05.10.2015 | 03:49 | 04:22 | 05:52 | 12:00 | 15:10 | 17:10 | 18:51 |
| 06.10.2015 | 03:51 | 04:24 | 05:54 | 12:00 | 15:08 | 17:07 | 18:48 |
| 07.10.2015 | 03:53 | 04:26 | 05:56 | 12:00 | 15:06 | 17:04 | 18:45 |
| 08.10.2015 | 03:55 | 04:28 | 05:58 | 12:00 | 15:03 | 17:02 | 18:43 |
| 09.10.2015 | 03:57 | 04:30 | 06:00 | 12:00 | 15:01 | 16:59 | 18:40 |
| 10.10.2015 | 03:59 | 04:32 | 06:02 | 12:00 | 14:59 | 16:57 | 18:38 |
| 11.10.2015 | 04:01 | 04:34 | 06:04 | 12:00 | 14:57 | 16:54 | 18:35 |
| 12.10.2015 | 04:03 | 04:37 | 06:07 | 12:00 | 14:54 | 16:52 | 18:33 |
| 13.10.2015 | 04:05 | 04:39 | 06:09 | 12:00 | 14:52 | 16:49 | 18:30 |
| 14.10.2015 | 04:07 | 04:41 | 06:11 | 12:00 | 14:50 | 16:47 | 18:28 |
| 15.10.2015 | 04:09 | 04:43 | 06:13 | 12:00 | 14:48 | 16:44 | 18:25 |
| 16.10.2015 | 04:11 | 04:45 | 06:15 | 12:00 | 14:45 | 16:42 | 18:23 |
| 17.10.2015 | 04:13 | 04:47 | 06:17 | 12:00 | 14:43 | 16:39 | 18:21 |
| 18.10.2015 | 04:15 | 04:49 | 06:19 | 12:00 | 14:41 | 16:37 | 18:18 |
| 19.10.2015 | 04:17 | 04:51 | 06:21 | 12:00 | 14:39 | 16:34 | 18:16 |
| 20.10.2015 | 04:19 | 04:53 | 06:23 | 12:00 | 14:37 | 16:32 | 18:14 |
| 21.10.2015 | 04:21 | 04:55 | 06:25 | 12:00 | 14:34 | 16:30 | 18:11 |
| 22.10.2015 | 04:23 | 04:57 | 06:27 | 12:00 | 14:32 | 16:27 | 18:09 |
| 23.10.2015 | 04:25 | 04:59 | 06:29 | 12:00 | 14:30 | 16:25 | 18:07 |
| 24.10.2015 | 04:27 | 05:01 | 06:31 | 12:00 | 14:28 | 16:22 | 18:05 |
| 25.10.2015 | 04:29 | 05:03 | 06:33 | 12:00 | 14:26 | 16:20 | 18:03 |
| 26.10.2015 | 04:31 | 05:05 | 06:35 | 12:00 | 14:24 | 16:18 | 18:01 |
| 27.10.2015 | 04:33 | 05:07 | 06:37 | 12:00 | 14:22 | 16:16 | 17:59 |
| 28.10.2015 | 04:35 | 05:10 | 06:40 | 12:00 | 14:19 | 16:13 | 17:57 |
| 29.10.2015 | 04:37 | 05:12 | 06:42 | 12:00 | 14:17 | 16:11 | 17:55 |
| 30.10.2015 | 04:38 | 05:14 | 06:44 | 12:00 | 14:15 | 16:09 | 17:53 |
| 31.10.2015 | 04:40 | 05:16 | 06:46 | 12:00 | 14:13 | 16:07 | 17:51 |



# Татарстан мөфтие конфессияара футбол матчында катнашты

Сентябрь башында Мәскәүдә төрле дин вәкилләре катнашында футбол матчы уздырылды. Мөселманнар, православлар, яһүдиләр, буддистлар ике командага бүленеп уйнады. Футбол уеннарын Россия мөселман эшкуарлары ассоциациясе Мәскәү шәһәре мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россия Үзәк Диния нәзарәте белән берлектә оештырды. Чара “Тату Россия - көчле ил” шигаре астында үткәрелде. Футбол уеннарында ТР МДН рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башка дини, иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашты.



# Каратэ буенча республика турниры үтте

Югары Ослан авылының “Чемпион” спорт комплексында каратэ буенча республика турнирында балалар, яшүсмерләр һәм олы яшьтәге кешеләр дә катнашты. 70 кг га кадәр үлчәмдә III урынны Казанның Тынычлык мәчете вәкиле Артур Саягфаров яулады.

ДИН вә Мәгыйшәт
6+
Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! (Корьән, 3:103)
Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Корьәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклагыз!

*Сентябрь саны, №9 (242)*

**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА

**РЕДАКЦИЯНЕҢ ҺӘМ НӘШЕР ИТҮЧЕНЕҢ АДРЕСЫ:**
420021, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 8 нче йорт
**Электрон адрес:** naubahar67@list.ru
**Телефон:** +7 950 326 38 36

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**
«Хузур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**
ҖМДНнең дәгъвәт бүлеге житәкчесе **Нияз САБИРОВ;**
Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).
**Нәшир:** «Хузур» нәшрият йорты (420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 8 нче йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" АҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9059**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **20 нче сентябрь** көнне **20.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **20.00 сәгатьтә.**